МБУ “Арская ЦБС”

Районная детская библиотека

# Чишмәләр челтерәп аксын!

# Пусть живут родники!



**Информ – дайджест**

## Су нинди телдә сөйләшә?

*«Техника молодежи» журналының быелгы 7 санында Татьяна Соловьеваның шушы исемендәге («На каком языке ?»)дигән мәкаләсе басылып чыкты. Анда сүз су турында бара. Һәм без барыбыз да бик белгән шушы гап-гади су турында* гаҗәп *нәрсәләр сөйләнә. Без бу мәкаләне ирекле текста тәрҗемә итеп, газета укучыларга тәкъдим итәргә булдык.*

Суның табигатьтә өч төрле каты, сыек һәм газ хәлендә булуы кешелек дөньясына узе яралганнан бирле билгеле. Ә менә соңгы вакытларда, икенче мең еллык ахырында аның тагын бер хәлдә - мәгълүмати хәлдә икәне дә беленде. Галимнәр беренче карашка искитмәле, хәтта ышануы да кыен булган нәрсәне ачыклады. Бактың исә, су үзен тере җан иясе кебек тота, аның гакылы, зиһене бар икән! Ул үзенә ясалган һәр тәэсирне хәтерли, гүяки тирә-якта булган бөтен хәлләрне аңлый, хәтеренә сеңдереп бара икән. Аурора, Азия һәм Америка галимнәре күп тикшеренүләр үткәрделәр һәм суның тирә-яктагы дөнья һәм хәтта Галәм белән мәгълүмат апмашуын ачыкпадылар. Һем бу идеялер беренче карашка гына фантастика төсендә булып чыкты. Бу уңайдан үткәрелгән беренче тикшеренүлердән үк безнең тирә-яктагы һәм барлык организмнар составындагы барча суның мәгълүматларны кабул итә, кабат- лый, саклый һәм тапшыра алуы беленде. Хәтта кешенең уе, сүзләре һәм халәте кебек бик нечкә нәрсәләрне дә! Шуның өстенә табигатьтәге суның һич көтелмегән тагын бер сыйфаты— яна алуы ачыкланды. Суның януы вакыт буенча бик озакка сузылган гамәл, әмма ул бара.

Россия, Казахстан, Швейцария, Израиль, АКШ, Англия, Австрия, Япония, Кытай кебек илләр галимнәренең ачышлары, будда дине монахларының күзәтүләре су белән хәтәр авыруларны дәвалап, хәтта һава торышы белән идарә итеп булу ихтималын белдерде. Сүз уңаеннан шунысында әйтергә кирәк, борынгы мәҗүси диннәр руханиларының һава торышына бары тик уй белән генә тәэсир ясый алулары кешелек тарихында билгеле гамәл.

Суның мәгълүмати системасының сизү сәләте бик көчле. Ул тирә-яктагы әйберләрнең формасын белә һәм кабул итә, музыка тыңлый, төрле фотография рәсемнәрендәге кешелерне танып ала, кеше сөйләмен һәм сүзләрнең мәгънәсен аңлый һәм хәтта шатлык яисә кайгыга кушыла ала. Япон галиме Эмото Масару шушы өлкәдә күп еллар буена эшли һәм суның мәгълүмати сыйфатын ышандыргыч дәлилләр белән раслады. Эмото Масару үткәргән тикшеренүләр искитмәле нәтиҗәләр бирде. Җир өстенә яуган кар бөртекләренең рәвешләре белән бер берсен кабатламавы һәркемгә билгеле. Әмма су катканда хасил булган кристалларның формасы суның ни дәрәҗәдә чиста булуына гына бәйләнмәгән, су янында нинди музыка башкарылуын, нинди сүзләр сөйләнүен, хәтта шундагы кешеләр аның хакында ниләр уйлавын, аңа әһәмият бирәме яки юкмы икәненә кадәр сизеп тора, шуңа карап кристалларын да узгәртә икән. Эмото суның үзенә карата кешелөрнең битараф булуын бер дә яратмый икәнен ачыклаган.

Гаҗәп нәрсәләрга тап булган бу галим! Ул өч банка ала, аларга дөге һәм аның өстенә су сала. Беренче банкадагы суга көн саен “рәхмәт сиңа" ди, икенчесенә “дурак син!” дип кычкыра, ә өченчесен бетенләй күрмәмешкә салына. Һәм ни диярсез?! Бер айдан соң беренче банкадагы дөгедән бик тәмле исләр килә башлый, икенче банкадагы дөге каралып бозыла, ә кеше бернинди игътибар салмаган өченче банкадагы дөге бөтенләй череп эштән чыга. Шулай итеп гади су адәмнәргә үзләре арасында мөнәсәбәтләр нинди булырга тиешлегенә бик ачык бер дәрес бирә. Эмото бер савытка су сала, аның янында төрле музыкалар уйната, аннары шул суны суытып туңдыра һәм хасил булган бозның структурасын рәсемгә ала. Кристаллар һәр рәсемдә үзенчә булып чыга. Бетховен, Моцарт симфонияләре, Шопен этюдлары бик матур, дөрес формалы кристаллар хасил булуга китерәләр. Шашкын итеп башкарыла торган авыр рок музыкасы коточкыч ямьсез, кырыйлары ерткыч кристаллар хасил итә.

Тикшеренүче үтә күренмәле савытка салынган су янына Гитлер дигән кабахәт рәсемен куя һәм шулай ук кире нәтиҗәгә ирешә.

Эмотоның ярдәмчеләре болай эшләп карыйлар. Кәгазь битлеренә ягымлы һәм усал сүзләр язалар да, шул сүзләрне эчке якка каратып, сулы пыяла банкаларга ябыштыралар. Шунда кеше ышанмаслык хәл була. Су нәрсәләр язылганны укый ала! Әйбәт сүзләр язылган банкада матур кристаллар, ә начар сүзләр язылган савытта гариплəнгән төстәге кристаллар ярала. Менә сиңа мә!

Ярату, рәхмәт әйтү сүзләре һәм төрле догалар уку тетрәндергеч нәтиҗәләр бирә. Доктор Эмото күзәтүенчә, судогаларны бигрәк тә ярата икән! Монд адога укучы кешенең нинди диндә булуы һәм кайсы телдә сөйләве әһәмиятле түгел. Су барысын да аңлый ала һәм бик матур кристаллар хасил итә. Төрле илләр галимнәре догаларның кешеләрне дәвалауда ярдәм итүенә ышанычлы дәлилләр таптылар. Һәм адәмнәргә генә дә түгел. Бактың исә догаларны безнең планетадагы барча тереклек ияләре дә кабул итә икән. Өстенә дога укылган суны эчсәләр үлеп барган җанварлар терелеп китә, андый суны сипсәң, шиңеп беткән үсемлекләр тернәкләнә.

Адәмбаласының хис вә тойгылары суга бик көчле тәэсир ясый алуы борынгы заманнардан ук билгеле. Бу гыйлемне мәҗүси диннәр руханилары һәм дәвалаучылар бик киң кулланганнар. Әле безгә якын заманнарда да кораб һәлакәтенә очраучылар бик яман сусагач һәм дингез суы төчегә әйләнсен иде дип бик тә теләгәч, ап-ачы диңгез суының төчегә әйләнү очраклары билгеле. Шулай итеп, Гайсә пәйгамбәрнең гади суны шәрабка әйләндерә алуы турындагы риваятьнең дөрес булу ихтималы бар.

“Су бөтен җир шары буйлап әйләнеп йөри, безнең тәннәребез аша үтә һәм тагын бөтен дөнья буйлап китә. Әгәренки без су хәтерендә сакланган бөтен мәгълүматларны укый алсак, нәрсәләрне генә белеп бетерер идек”, — Эмото Масару әнә шулай уйлый.

Мәгълүм ки, су молекулалары хәтта йолдызара киңлекләрдә дә бар. Шуның өстенә су кометалар, Кояш системасындагы күпчелек планеталар һәм аларның иярченнәре составына керә. Һәм, бик **мөмкин,** ул галәмнең Җирдәге гамәлләр белән идарә итүендә дә зур урын тотадыр. Ул тәкъдирдә җимергеч су басулар һәм давыллар суның ке- шеләрдән алган ямьсез мәгълүматларын кире кайтарып бирүе була. Агрессия, явызлык. сугышлар, үзара көнләшүләр кешелек дөньясы өчен һич кенә дә эссез үтеп китми. Су безнең өчен составындагы хәтәр кушылмалары, бациллалары, вируслары белән генә куркыныч түгел. Ул безгә, беренче чиратта, без ана үзебез биргән мәгълүматларны кире кайтаруы белән куркыныч.

Ә су бөтенесен дә хетерендә тота! Фаразларга була, океаннарда үз тирәнлекләрендә моннан миллион еллар элек яшәп“ киткән җан ияләре турында хатирәлер саклана торгандыр. Су үзе дөнья яралганнан бирле “очраткан” барча бактерияле: һәм вирусларны хәтерендә тота Шуның өстенә галимнәр мондый» турында да мәгълүматлар салынган.

Физик яктан алып караганда кешенең гәүдәсе сиксән процент судан тора. Тәндәнге нәтиҗәгә киделәр, су хәтерене үткәннәр турында гына түгел ә киләчәк заманнар барлык гамәлләрдә, теләсә касы органда су катнаша. Биологик яктан алып караганда без- картаю ул тәнебезнең суга ярлылануы, күзәнәкләрдә һәм алар арасында сыеклыкның кимүе, үлем исә кеше тәнендә сыеклыкның илле процентган да түбән төшүе.Тагын шунысы да кызыклы, кеше тәнендәге суның структурасы һәр вакытта шул кеше үзе туган урындагы су структурасына тәңгәл килә. Һәм бу су шул урындагы туфрак, биологик һәм энергетик мөмкинлекләр турында мәгълүматларны саклый. Шулай итеп “Ватан” төшенчәсе кутәренке сүз генә түгел, ә гаять тирән мәгънәле, физик эчтәлекле сүз булып чыга. Менә шуңа күрә дә без һәрберебез үзебез туган җирне гомеребез буена оныта алмыйбыз, аның белән эчке элемтәбез һичкайчан өзелми. Монда шунысын да истә тотарга кирәк, организмда суның аз булуы кешегә кире тәэсир итә, аны хәлсезләндерә, ә артык булуы шулай ук әйбәт түгел, йөрәк-тамырлар системасына авырлык китерә, кеше еш тирли, тәндәге кирәкле тозларны һәм эрегән хәлдәге витаминнарны югалта.

Суның, без барыбыз да бик әйбәт белгән гап-гади суның мондый үзенчәлекләре ачылу киләчәктә тагын нинди үзгәрешләргә, ачыш-табышларга китерер? Моны төгәл фаразлавы кыен. Төрле илләр галимнәре бу уңайдан инде җиң сызганып эшлиләр. Шулай итеп, киләчәктә, ә бәлки якын киләчәктә зур үзгәрешләр булуы ихтимал.

Ә безгә, гади кешеләргә, табигать могҗизасы булган суны ихтирам итәргә, аның чисталыгын сакларга гына кала.

**Материалны Р. ФӘИЗОВ әзерләде. Су нинди телдә сөйләшә?// Арча хәбәрләре.- 2007.- № 91-92.- 28 июль.- 4 бит.**

# Авылым чишмәләре

Җир йөзендәге һәр кешенең үзенең кечкенә туган иле туган ягы бар. Ул синең авылың, син яши торган урам, йорт, ишегаллары, су буйлары, чана шуа торган кар таулары, чылтырап аккан чишмәләре, урманнары, кырлары. Син шул ишегалларына чыгасың, урманнарга барасың, чылтырап аккан чишмәләрнең салкын суларын эчәсең.

Табигатькә җан кертүче елга, күл, инеш, диңгез, океаннарга тормыш өрүче елгаларга һәм **чишмәләргә бик бай Арча районындагы Хәсәншәех авылы.**

Безнең авылыбызда риваятьләргә бай чишмәләр күп. Алар авылыбызның кабатланмас бизәге. Безнең бу язмабыз чишмәләребез тарихы турында.

Беренче сыйныфка укырга кергән көнне класс җитәкчебез безне **Изгеләр чишмәсенә** алып барды. Авылыбызның аксакалы Гатуф абый Әхмәтов чишмә тарихы белән таныштырды. Авылга нигез салучы Хәсән карт каберлеге тирәсеннән чишмә бәреп чыккан. Шуңа күрә аны авыл халкы Изгеләр чишмәсе дип атаган. Бу чишмәнең шифалы суын алырга дип төрле төбәкләрдән киләләр.

**Зөбәйдә чишмәсенең** дә тарихы бик кызыклы. «Сиңа кайттык, Зөбәйдә чишмәсе» дигән мәкаләдә аның тарихы турында түбәндәгеләр язылган: «Бер гаиләдә яңа туган ике кыз балага Зөлхиҗә һәм Зөбәйдә дип исем биргәннәр. Үсеп, аякка басарга да өлгермәс борын аларнвщ әти-әниләре үлеп киткән. Тормыш авырлыгын бик иртә татыган ятим кызлар кичләрен чишмә янына киләләр дә, суга вак ташлар атып, гел хыялларга чумып утыралар икән. Зөлхиҗә, үсеп җиткәч, мул тормышта яшәү, бай егеткә кияүгә чыгу турында уйлый. Ә Зөбәйдә, киресенчә, байлыкка кызыкмый, ул Ходайдан алтын- көмеш түгел, тазалык-саулык сорый икән. Еллар үтә, кызлар, буйга җитеп, үз теләкләренә ирешәләр. Зөлхиҗә бай хатыны була. Тик бәхете генә юк, сәламәтлеге какшап, картаерга да өлгерми үлеп китә. Ә Зөбәйдә исә, байлыкта йөзмәсә дә, үзенә озын, бәхетле тормыш бүләк иткән чишмәгә рәхмәт укып, дөньядан ямь табып яши. Шуңадыр, ул үлгәч, авылдашлары сулыкны Зөбәйдә чишмәсе дип атап йөртә башлыйлар». **Киндер күле** чишмәсенең тарихын безгә тарих укытучысы сөйләде. Чишмә бәреп чыккан җирдә генә күл дә булган. Бу күлдә элек җитен җебетеп киндер сукканнар. Хәзерге вакытта күл кипкән, ә чишмә сакланып калган. Яз җитү белән без ул чишмәне чистартырга ашыгабыз.

**Казаклар чишмәсенең** дә тарихы кызыклы. Элекке вакытларда бу чишмә янында Казаклар җыены үткәрелгән. Анда старосталар авыл тормышына кагылышлы мәсьәләләрне хәл иткәннәр. Печән бүлгәннәр, көтү чыгару турында сөйләшкәннәр. Бу чишмә әле дә саклана, халыкка хезмәт итә.

Чишмәләребез челтер-челтер аккан вакытта нидер сөйлиләр кебек. Чишмәләрнең сөйләшүләренә, җырлауларына таң калып тыңлап торырга яратабыз. **Изгеләр чишмәсе** болай ди:

- Минем суым бик шифалы, изге һәм бик тәмле, суымны алырга дип бик ерак-ерак җирләрдән кайталар. Мин Хәсәншәех халкына намус белән хезмәт итәм. Халкыма бик рәхмәтлемен, мине карап, тәрбия кылып торалар. Авылыбызның асыл егетләре — Татарстан авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов һәм «Ватан» күмәк хуҗалыгы рәисе Мансур Әхмәтов манаралап бура эшләттеләр, авыл эчендә кызыл, ак кирпечтән ял итү урыны төзеттеләр. Зур күлнең ярлары плитә белән тыш- ланган, сукмакларга таш җәелгән, күл уртасында фонтан атып утыра. Ә авылга нигез салучы изге Хәсән хәзрәткә һәйкәл куелды.

Бу сүзләргә **Зөбәйдә чишмәсе** кушыла:

- Суымның тәмлелеге буенча миңа тиңнәр юк. Киң күңеллелеге, кешеләргә ярдәмчел булуы, эш сөючәнлеге, чибәрлеге белән халык күңелен яулаган Зөбәйдәнең дәвамчысы мин. Дөньяга чыгып ага башлавыма күп гасырлар үтте. Шул вакыт эчендә минем янымда кемнәр генә булмады?! Типсә тимер өзәрдәй пәһлеван егетләр, тал чыбыгыдай нечкә билле чибәр кызлар, ирләрен яу кырында югалткан аналар, гомерләрен тигезлек белән үткәргән әби-бабайлар... Авыл халкының миңа да ихтирамын һәм хөрмәтен кызганганы булмады. 2005 елда мине, беркайда булмаганча, борынгылар рухына туры китереп, авылдашларымны шатландырырлык

итеп, авылның гайрәтле ирегете - «Татарстан сөте» акционерлык. җәмгыяте генераль директоры Вагыйз Минһаҗев төзекләндерде. **Казаклар чишмәсе** исә:

- Инде миңа да игътибар итегез, исемем - Казаклар. Минем суым да тау астыннан ургылып чыга. Җөй көне юлаучыларга юл күрсәтәм, җиләк җыючылар, көтү көтүчеләр, суымны эчеп, арган тәннәренө сихәт алалар, -- дип челтери.

Ашыкмый гына Киндер күле чишмәсе телгә килә:

- Без ага башлаганга бик күп еллар үтте, инде суым саега, элекке матурлыгым югала бара. Ә бит ул заманнарда минем күлем, киндер юучы нечкә билле кызлар, уңган апалар сөйләшүеннән шау-гөр килеп тора иде. Кешелек тарихында су чыганаклары, бигрәк тә чишмәләр кадер-хөрмәткә лаек булган. Чишмәләр буенда һәрвакыт чисталык-пөхтәлек, тәртип иде. Су чыганакларын пычратучылар зур гөнаһлы ке- шеләрдән саналган, аларны хәтга җәзалаганнар да. Чөнки чишмәләр кешелекнең яшәү чыганагы, аларның «саулыгы» чишмәләргә һәм башка су чыганакларына бәйле.

Без, Хәсәншәех урта мәктәбе укучылары, шушындый матур чишмәләрне шефлыкка алдык. һәр чишмәгә аерым класслар беркетелде, аларны һәрвакыт карап торабыз.

**«Туган якны өйрәнү» түгәрәге әгъзалары,Арча, Хәсәншәех. Авылым чишмәләре // Шәһри Казан.- 2009.- №227.- 9 декабрь.- 6 бит.**

## “Тәнгә - җанга сихәт, дәрман биргән чишмәләрнең кадерен белегез!”




***Су... Бер йотым су...Чүлдә яшәүчеләр өчен шул бер йотым су кайвакыт тау-тау алтын бәясеннән дә кыйммәтрәк йөри. Шөкер, безнең алай суга тилмергәнебез юк. Күрәсең, шуңа күрә елга-инешләргә карашыбызда икенче төрлерәк...***

Бүген бик еш шундыйрак сүзләр ишетергә туры килә: “Әлек фәлән чишмәсенең суы тәмле була иде, шуны чистартмыйлар бит, авыл Советы ни карый икән?!” Мондый сүзләргә карата күңелемдә күптән ризасызлык яши инде. Әби-бабаларыбыз элек авыл Советын көтеп тормаган бит, үзе белеп чистарткан, улакларын төзәткән. Моның өчен кеше рәхмәтен дә, акча да өмет итмәгән. Чөнки чишмәләрне төзек тоту элек электән изге эш саналган. Ә бабаларыбыз изгелек эшләүнең тәмен, рәхәтен белгәннәр.

Шунысы куандыра: бүген ул традицияләр кире кайта. Изгелек кылырга омтылучылар саны да арта. Әнә бит Югары Курса авылы егете Дамир Хәбибуллин үз йортлары каршыннан агып яткан чишмәне рәтләп, йортын тезеп куйган. Үткән шимбәдә әнә шул чишмәне ачып та куйдылар. Муниципаль берәмлек башлыгы Рәмзия Вафина: “Бу чишмәнең барлыгын белгәнемә менә инде 25 ел була. Тик аның әлегәчә исеме булмавын бүген генә белдем”,-дип сөйләде. Кызык: бу гомер чишмә аккан, исеме булмаган. Ләкин кемдер аны карап торгандыр бит инде. Югыйсә, чишмәләргә күбрәк аны чистартып, карап торган кешенең исемен кушалар. Ә бу очрак әле генә әйтеп үткән фикеремә дәлил булып тора. Бу бәйрәмдә чишмәгә исем дә кушылды. Авыл халкы беравыздан аңа **“Игелек”** исемен бирделәр. Теләкләре-бу чишмә гомер- гомергә кешеләргә игелек кылган, суы җанга-тәнгә дәва биргән, алга таба да игелеге бетмәсен, суын эчеп илгә игелекле ул-кызлар үссен. Ә игелеккә килгәндә, анисына да шөкер, Югары Курсада андый егет-кызлар әле бар. Өч авылга бер мәчет булмавы күпләрнең эчен пошыра иде. Иншаллаһ, башы булгач, ахыры бер булыр, ди халык. Ә эш башланган инде: шул авыл егете Илһам Хисамиев мәчеткә 60 мең сум акча биргән. Хәзер күп нәрсәне оешканлык, җитәкчеләрнең ярдәме хәл итәчәк...

Бәйрәм дәвам итте, чишмә суыннан чәй кайнатып, авылдашлар чәй-коймак белән сыйландылар, аулак өйдә күңел ачтылар, рәхәтләнеп концерт карадылар. Ә “кичке уенга” Равил Габдрахманов, Рәсимә Сәфәргалиева да чакырылган иде.

Авыл көне бәйрәмендә шулай ук мәдәният бүлеге начальнигы И.Ф.Котдусов, “Курса” хуҗалыгы җитәкчесе Р.Г.Гыйлаҗетдинов та катнашты.

Әнә шулай бәйрәм итте ул көнне курсалылар. Чишмә суыннан тән, җан дәвасы алдылар, авылдашларының игелегенә куандылар рәхмәтләр укыдылар.

***Р.ЛАТЫЙПОВА. Тәнгә - җанга сихәт, дәрман биргән чишмәләрнең кадерен белегез!//Арча хәбәрләре.- 2007.- №84.- 11 июль.- 2 бит.***

# Дорожите родниками.

***Вода... Глоток воды... Для жителей пустыни глоток воды иногда дороже, чем целые горы золота. Слава богу, мы не испытываем мучение из-за нехватки воды. Поэтому, наверное, у нас отношение к речкам и родникам несколько иное.***

Сейчас частенько можно слышать такие слова: «Раньше вода у такого- то родника была такой вкусной, никто не очищает, не благоустраивает его, и куда смотрит сельский Совет?!» В душе я всегда была не согласна с таким мнением. Ведь наши предки раньше не ждали, пока возьмется за дело сельский Совет, а сами чистили, поправляли желоба. Не ждали чьих-то благодарностей и денег. Потому что благоустройство родников издавна считалось священным делом. А наши предки знали вкус и удовлетворение от совершения доброго дела.

Радует то, что традиции сегодня возрождаются. Растет и число желающих совершать благие дела. Вот Дамир Хабибуллин из деревни Верхняя Корса. Он привел в порядок территорию родника, находящегося перед их домом, построил над ним «домик». В прошлую субботу состоялось открытие этого родника. Глава муниципального образования Рамзия Вафина сказала: «Я уже 25 лет знаю о существовании этого родника. Но только сегодня узнала, что до сих пор у него нет названия». Интересно: родник был, а названия не было. Но ведь кто-то ухаживал, благоустраивал его. Обычно называют по имени того, кто очищает, присматривает за родником. Этот случай — подтверждение высказанного мною мнения. На этом празднике роднику дали и имя. Сельчане единодушно назвали его «Игелек» (буквально «Милосердие»), Пожелание—пусть этот родник, служивший долгие годы людям, радовавший студеной питьевой водой, и впредь творил добро людям, чтобы пользующиеся его водой юноши и девушки стали милосерднее. А что касается благотворительное, то это качество присуще жителям Верхней Корсы. Многих волновало то, что на три деревни не было ни одной мечети. Говорят, лишь бы было начало, конец будет, или иначе: начало—половина успеха. А дело уже начато: жители этой деревни Ильгам Хисамиев дал на строительство мечети 60 тысяч рублей. Сейчас дело зависит от организованности и поддержки руководства раздник продолжился, вскипятили чай из родниковой воды, угостили сельчан горячими блинами с чаем, развлекались на посиделках, с удовольствием посмотрели концерт. А на «вечерние игры» пригласили и Равиля Габдрахманова с Расимой Сафаргалиевой.

На празднике «День села» присутствовали также начальник отдела культуры И.Ф.Кутдусов, руководитель хозяйства «Корса» Р.Г.Гилязутдинов.

Вот такой праздник организовали в этот день корсинцы. Испили родниковой воды, которая дала усладу для души и тела, порадовались добрым деяниям односельчан, выразили благодарности.

***Р.ЛАТЫПОВА. Дорожите родниками // Арский вестник.- 2007.- №84.-11 июля.-***

***2 стр.***

## *Үзебез һәм киләчәк буыннар өчен*



***Су һәм тормыш—аерылгысыз төшенчәләр. Чиста табигый су гади тормыш кына*** **тугел,** ***ә аннан да зуррак, ул әлеге тормыш турында мәгълүмат бирүче дә. Һәр кешенең үзенең яраткан чишмәсе,*** **инеше** ***яки елгасы була, алар турындагы мәгълүмат аның геналары дәрәҗәсендә салынган. Шуңа күрә без чит җирләрдәге суга озак күнегә һәм безгә якын булган чыганакларның тәменнән ләззәтләнеп, суын эчеп туя алмыйбыз.*** Әмма еш кына без кайчандыр көч бирә торган һәм менә дигән сулы чишмә һәм коеларның тәмсез, ә кайвакытта болганчык, начар исле чыганакка әйләнүен күреп уфтанабыз.

Кеше эшчәнлеге нәтиҗәсендә җир шарында эчәргә яраклы төче су запасы елдан-ел кими. Күп илләрдә инде эчү өчен су җитми, дистәләгән илдә халык эчү максатларында бары тик алдан чистартылган шешәле суны файдалана.

Россия әлегә ифрат дәрәҗәдә җир өсте һәм җир асты төче су запасларына ия булган аз илләрнең берсе. Ләкин табигать чыганакларына карата тупас, хуҗасызлык, киләчәкне уйламыйча эш итү, булган чыганаклардагы суларны контрольсез файдалану Россия- нең күп регионнарында су запасларының кимүенә, сыйфаты начарлануга китерде.

Әлеге шартларда безнең республика да искәрмә була алмый. Татарстанның нефть чыгаручы районнары, җир асты су чыганаклары пычранганлыктан, йөзәрләгән километрлардан сүүткәргечләрдән килгән һәм күп тапкырлар химик һәм биологик чистарту үткән суны файдаланырга мәҗбүрләр. Билгеле, әлеге суның көч бирү сыйфат- лары, табигый структурасы турында әйтеп тә торасы юк.

Бу мәсьәләдә безнең районда хәлләр ничек, су чыганакларын саклау һәм киләчәктә файдалану өчен ниләр эшләнә?

Арча районы үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системасы җитәрлек киң үсеш алган территорияләрнең берсе. Нигездә һәркайда иң ышанычлы, тышкы пычрану чыганакларыннан сакланган җир асты сулары файдаланыла.

Бүгенге көндә районда 82 артезиан коесы эшли, алардан су 230 км. сүүткәргеч торбалар аша район халкына, промышленность һәм авыл хуҗалыгы объектларына бирелә. Хәзерге вакытта мондый су чыганаклары булу зур байлык. Әйе, нәкъ менә байлык, чөнки су бүген бәһасе булган товар һәм ул көннән-көн кыйммәтләнә генә. Ләкин бүген әлеге табигать биргән байлыкка ничек каравыбызны да әйтми булмый. Су белән тәэмин итүче скважиналарның, сүүткәргеч корылмаларның күбесе бүген күңелсез хәлдә.

Иварның торышы, тотылышы халыкны сыйфатлы су белән тәэмин итүгә дә, җир шарындагы су горизонтларын пычранудан сакауга да ярдәм итми. Скважина- моның яртысыннан азы гына тиешенчә өстәләп алынган, су агыза торган канал тышкы тәэсирләрдән һәм чит кешеләр кертми торган павильоны булган ванктар саклау зонасына ия. Күп авылларда су белән тәэмин итү системасына хезмәт күрсәтү буенча тиешенчә укулар медицина комиссиясе үткән җаваплы кешеләр юк, ведомство производство «контроле программасы юк, су сыйфаты тикшерелми, профилактик ремонт эшләре алып барылмый, су белән тәэмин системасын юдыру, дезинфекцияләү үткәрелми.

Чыганакларны һәм суүткәргеч корылмаларны тоту, халыкка бирелә торган суың сыйфаты буенча тапәпләр саны кагыйдәләр һәм “Зоны санитарной охраны источни**ке** водоснабжения и водопроводов питьевого назначения» и «Питьевая вода. Гигиенические требования к качеству воды централизованных систем питьевого водоснабжения. Контроль качества» дигән нормалар белән регламентланган. Әлеге санитар кагыйдәләрне үтәү гражданнар, шәхси эшмәкәрләр һәм юридик шәхесләр өчен дә мәҗбүри.

Шуңа күрә суүткәргеч корылмалар балансга торган авыл хуҗалыгы предприятиеләре житәкчеләренә, авыл муниципаль берәмлекләре башлыклары, авыл башкарма власте вәкилләре белән берлектә, санитар-эпидемиологик һәм экология күзәтчелеге органнары тарафыннан өстәмә күрсәтмәләр һәм административ чаралар кулланунны көтмичә, су җыйнау һәм суүткәргеч корылмаларны ашыгыч рәвештә тиешле, санитар нормалар таләпләренә жавап бирерлек хәлгә китерергә кирәк. Ә алар түбәндәгеләр: —су чыганагының (скважина) зонасын әйләндереп алырга һәм «Санитар саклау зонасы» дигән язу куярга;

—әлеге территорияне җир өсте сулары агып китәрлек итәргә, әйләнәсенә су агу өчен каналлар ясарга;

—санитар саклау зонасын яшелләндерергә;

—скважиналар өстенә павильон ясарга, скважина торбалары тирәсен бетонларга;

—санитар саклау зонасында беренче, икенче һәм өченче поясларда грунтның һәм жир асты суларының пычрану чыганакларын бетерергә;

—су җыйнагычларны системалы контроль өчен аппаратура белән җиһазларга;

—су үткәргеч корылмаларга ревизия, юдыру һәм дезинфекцияләү үткәрергә;

—су колонкаларына профилактик ремонт ясарга, карау коеларының герметик булуын тәэмин итәргә;

—су белән тәэмин иту системасына рөхсәтсез ялгауны будырмаска;

—су сыйфатына ведомство производство контроле программасын эшләргә һәм расларга, тикшерүләр үткәрүгә килешүләр төзергә;

—су белән тәэмин итү системасына хезмәт күрсәтү өчен җаваплы кешеләр билгеләргә, аларны һөнәри һәм гигиеник укыту, медицина тикшерүе үткәрергә;

—чыганакларның һәм су белән тәэмин итү системасының санитар нормаларга һәм кагыйдәләр тапәпләренә туры килүе турында санитар- эпидемиологик бәяләмә һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга хокук бирә торган лицензия алырга.

Әлеге чараларны үзвакытында һәм сыйфатлы итеп үтәү халыкны сыйфатлы эчә торган су белән тәэмин итәргә, җир асты чыганакларының торышы өчен тыныч булырга һәм аларны якын елларда гына түгел, ә безнең районда яшәүчеләрнең киләчәк яңа буын- нарына да файдалану мөмкинлеге бирер.

***Ф.ЗӘЙНУЛЛИН****, «Роспотребнадзор»ның Татарстан Республикасы буенча территориаль идарәсенең Биектау районындагы территориаль бүлеге начальнигы урынбасары.* ***Үзебез һәм киләчәк буыннар өчен//Арча хәбәрләре.- 2006.- №67-68.- 17 июль.- 2,7 бит.***

# Доброе дело не забудется

**С давних пор люди считали родники, колодцы святыми. Названия многих из них через века дошли и до нас. Названия даны не зря, эти люди в свое время ухаживали за данными родниками, колодцами, о них ходит множество легенд.**

Водоемы со временем стареют, покрываются илом, зарастают травой, они мельчают, затем исчезают совсем. К счастью, вокруг нас много хороших людей, с их помощью творится много добрых дел.

В прошлую пятницу и стар и млад в Нижних Метесках собрались на месте, в народе названном «Русский колодец». Этот источник, скрывающийся среди ивовых зарослей при въезде в деревню, можно назвать и колодцем, и родником. В свое время он обеспечивал деревню самой вкусной водой. Его вырыл, сделал сруб человек русской национальности, к сожалению, имя его не сохранилось, но сделанное им бессмертно.

Даниял Фасахиев, который родился и вырос в этой деревне, для нее сделал много добра. Большой вклад вложил в строительство мечети, обновление кладбищенской ограды. Очередь дошла до «Русского колодца». Жители деревни Нурислам Гафиятуллин, Камиль Фасахиев, Наиль Шаймуллин, Динар Зиганшин очистили окрестность от куста, поглубже вырыли колодец, благоустроили, над ним построили «кукольный домик». Чтобы получить воду, нужно лишь нажать на кнопку. С наступлением темноты автоматически зажигается свет, когда светлеет, гаснет. Над ручейком проложен железный мостик.

Возрождение колодца торжественно отметили. На скамейках сидят женщины, которые всю жизнь носили воду из этого колодца. Столы ломятся от яств. То, что торжество совпало с Днем пожилых, что на небе весело сияло солнце, еще более украсило праздник.

Первым слово предоставили уважаемому человеку деревни, имам-хатибу Накипу Шигабиеву. По религии считается, что уважительное отношение к воде — это одно из самых святых действий. Глава Кунербашского сельского поселения Фаргат Сиразетдинов, руководитель отделения «Игенче» Талгат Закиров, Салим Гимадиев, долгие годы проработавший в этом хозяйстве руководителем, приехавший поздравить пожилых от имени администрации района, выразили свои наилучшие пожелания. Приятно было видеть участие на торжестве школьников.



В этот день поздравлений было много.

**И.САХАПОВ. Доброе дело не забудется // Арский вестник.- 2008.- №120.- 8 октября.- 3 стр.**

# Гафия чишмәсе

Чишмәләр кайчандыр су алу гына түгел, яшьләрнең очрашу, вәгъдәләр бирешү урыны да булып саналган. Тормыш үзгәргән саен бу көннәр акрынлап артта калган. Эмма һәркайда чишмә изге урын буларак игътибар үзәгендә булган. Миржәм авылы да чишмәләргә бай як. Шуларның берсе — елга тебендә үк диярлек урнашканы, югары оч чишмәсе.

— Бик йомшак, тәмле сулы ул. Элек бар да суны чиләк-көянтә белән шуннан ташыды. Берзаман авылга су керде. Чишмәгә юл онытылды дисәм...Юк, әлеге чишмә авыл халкын магниттай үзенә тартты, — ди чишмә тау башындагы йортта гына яшәүче Фирдәвес Сибгатуллин.

Ул үзе шушы авылда туып-үскән, гомер иткән. 70нче елларда өйләнмәгән егет ремонтлап та йөри әле шул чишмәне. Тик күпме гомер үткән бит. Чишмә дә тәмам эштән чыккан, ярым җимерек хәлгә килгән. Бу күренешкә эче пошкан Фирдәвес абый борчуга төшә. Үзенең генә көче җитә торган эш түгел, Нишләргә? “Шунда кылт итеп исемә Рүзәл Гәрәев килеп теште. Әнисе Сания апа безнең авылныкы бит. Бәлкем, каршы килмәс. Бардым. Гозеремне әйттем. Бераз булса да рәткә кертергә булышуын сорадым”, — ди Фирдәвес абый.

- Булгач-булгач яхшылап эшләргә кирәк аны, — ди Рүзәл Баязитович һәм берсүзсез ярдәм итәргә ризалыгын белдерә.

7-8 “КамАЗ” машинасы белән таш кына кереп китте. Кызыл кирпечтән йорт эшләп куйдылар, менә дигән материалдан түбәсен яптылар, тутыкмас тимердән улагын эшләделәр, төшү юлына таш түшәделәр. Барысы артыннан Рүзәл Гәрәев үзе йөрде. “Арча автотранспорт предприятиесе” акционерлык җәмгыяте егетләренә авылдан Ришат Әхмәдиев, Дамир Ибраһимов, Фидаил Сибгатуллин, Равил Сабиров булыштылар, — дип сөйли сеенә- сөенә Ф.Сибгатуллин.

Чишмәгә Сания апаның әнисе исемен куялар. Аның йорты шушы тирәдә генә булган. Гафия чишмәсе капкасына ике яклатып шигырь язылган

*“Күңелләрем ачтың чишмәм,*
*Суың тәмле, ләззәтле*
*Эчкән суың көч-хәл өсти*
*Бөтен кеше рәхмәтле'*

Авыл халкы тәмле сулы чишмәгә генә түгел, аны торгызган һәм шундый горурланырлык күркәм хәлгә китергән Рүзәл Гәрәевка да рәхмәтле. Изгелек ул һәрвакыт кешенең үзенә игелек булып кайта. **Гафия чишмәсе** әле озак еллар авыл халкын сөендерер.



**Г.Зиннәтова. Гафия чишмәсе // Арча хәбәрләре.- 2008.- №118-119.- 3 октябрь.- 6 бит.**

# Яхшылыкны халык онытмас

Элек-электән халык кое-чишмәләрне изге итеп санаган. Аларның күбесенең исемнәре гасырлар аша үтеп бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән. Әлеге исемнәр юкка гына бирелмәгән, бу кешеләр үз вакытында шул кое-чишмәләрне карап торучылар булганнар, алар турында бик күп риваятьләр яши.

Сулыклар да вакыт үтү белән картая, ләм, үлән каплый, саегалар, тора-бара юкка чыгалар. Бәхеткә каршы, тирә-юнебездә игелекле бәндәләр дә аз түгел, алар ярдәме белән бик күп матур эшләр башкарыла.

Узган җомгада Түбән Мәтәскә авылының олысы кечесе **"Рус коесы"** дип йөртелгән урынга җыелды. Авыл башындагы елгада тал-тирәкләр арасында яшеренеп яткан бу су чыганагын кое дисәң дә, чишмә дип атасаң да ялгыш булмас. Заманында авылны иң тәмле су белән тәэмин итеп торган ул. Казучысы, буралаучысы рус кешесе булган, кызганычка каршы, бу кешенең исеме билгесез, әмма аның кылган гамәле үлемсез.

Шушы авылда туып-үскән Даниял Фәсәхиев авылы өчен күп яхшылыклар эшләгән кеше. Мәчет салуда, зират коймасын яңартуда аның өлеше зур. Инде менә "Рус коесына" чират җиткән. Шушы авылда яшәүче Нурислам Гафиятуллин, Камил Фәсәхиев, Наил Шәймуллин, Динар Җиһаншин тирә-юньне куаклардан чистартып, коены тирәнәйтеп, төзекләндереп "курчак өе"нә керткәннәр. Суны да хәзер төймәгә басып кына аласың. Караңгы төшүгә үзеннән-үзе ут кабына, яктыргач сүнә. Инешне чыгу өчен тимердән басма салынган.
Коеның яңадан тууын матур тантана белән билгеләп үттеләр. Эскәмияләрдә шушы коедан су ташып гомер кичергән әбиләр, апалар утыра. Өстәлләрдә мул ризык. Тантананың Өлкәннәр көненә туры килүе, күктә кояш балкуы ямь өстенә ямь өсти.

Беренче сүзне авылның иң хөрмәтле кешесе, имам- хатиб Нәкыйп Шиһабиев ала. Дин дә суга хөрмәт белән карауны иң изге гамәлләрнең берсе дип өйрәтә. Купер- баш авыл җирлеге башлыгы Фәргать Сираҗетдинов, "Игенче" бүлекчәсе җитәкчесе Тәлгать Закиров, район хакимияте исеменнән өлкәннәрне котларга килгән, шушы хуҗалыкта озак еллар җитәкче булып эшләгән Сәлим Гыймадиев иң матур теләкләрен ирештерделәр. Тантанада мәктәп укучыларының катнашуы да күңелле булды.

**И.САХАПОВ**. **Яхшылыкны халык онытмас // Арча хәбәрләре.- 2008.- №120.- 8 октябрь.- 3 бит.**

# Савап кылсаң - су белер

Иртәнге йокыңнан уянганда үзеңнең исән-сау булуыңа куана белу, әйләнә-тирәне күрә алу, матурлыгына- тынычлыгына соклана белү - бәхет ул. Менә шуннан башлана да инде көнеңнең, эшеңнен, уңышлары. Мин 1931 елда туып, Кенәбаш авылында үстем. Авылымның без үскәндәге табигый матурлыгын (исемдә калганнар буенча) күз алдына китерү генә дә миңа олыгайган көнемдә яшәргә көч бирә.

Безнең авыл ике урман (Югары һәм Түбән урманнар дип исемләдек) куенына сыенып, тау башында утыра. Урманнарны бер-береннән биек тау итәгеннән агып ятучы Кенә инеше аерып тора. Без балалар өчен ул чакларда Тау асты исеме белән йөртелә торган аерым бер серле дөнья бар иде... Аның нәкъ уртасыннан, тау өстендәге урам белән янәшә җәелгән инешнең аргы ягы - чабылдык болын, ә бирге ягында дистәләгән чишмә... Шунда ук бала-чагасы, каз-үрдәге, бозавы дигәндәй. Тавы да үзенчәлекле, төрле- төрле ташлардан тора. Чишмәгә алып төшүче сукмак шул ташлар арасыннан үтә. Безнең якладагы бер генә төбәктә дә күргәнем юк - авыл буйлап санаганда алты урында атлы арба йөрерлек итеп таш чокып тау юллары салынган. Түбән оч тавы юлы һәм ике урыннан “Шәрәкә” чишмәсенә килә торган тау юллары, текә тау юлы, те- гермән тавы юлы, ферма һәм су әвеслегенә төшә торган тау юлы. Алар безне урман һәм иген кырлары белән тоташтыра. Ут-күздән саклану чараларына җаваплы кеше Шәкүр абый бу юлларны һәр язда төзәткәләп тора. Юлларны елның теләсә кайсы вакы- тында су алырга төшәрлек һәм елга аркылы ныгуны тәэмин итәрлек хәлгә китерү- аның җаваплылыгында. Ә күпер бер генә урында - ул тегермән бәясе өстеннән үтә. Авылны гына түгел, тирә-юньне төзек, чиста, унайлы итеп тоту өчен бөтен көчен, тырышлыгын куйган Шәкүр абый хакында китаплар язарлык.

Ә безнең чишмәләр нинди?! Эре бөртекле алтынсыман ком арасыннан тыйнак кына ага торган бер “Саз чишмәсе” дигәне үзе генә дә ни тора! Ком белән кызлар савыт-саба, өй бүрәнәләрен чистарта, ышкып юылган өй эченә аерым хуш ис - агач исе тарала... Кер юа торган порошок исе түгел инде ул! “Түбән оч чишмәсе”, “Шәрәкә чишмәсе”, “Мәсхүт чишмәсе”, “Утлы таш чишмәсе” һәм “Тал чишмәсе”нә исемсез ваграк чишмәләр дә килеп кушыла. Ни дисәң дә, әүвәл кеше табигатькә якынрак булган, аның уй-хисләре һәм күңеле кешелекле булган.

Безнең авыл инешен мин үскәндә, аның башланган урынына бәйләп, “**Ак чишмә суы**” дияләр иде. Кайбер китапларда **Хотня суы** дип тә язалар. Тарихи документларда һәм 1884 елгы картада “Кенә суы” дип язылган. Авылыбызның — Кенәбаш, күрше авыл- ның Түбән Кенә булуы да шушы инеш исеменә бәйле икәне дөреслеккә туры килә. “Кенә” сүзе маричадан алсу һәм саргылт чәчәкләр аланлыгын аңлата. Әле мин үскәндә инеш буе чабылдыклары алсу төстәге дебет чәчәкләре белән бизәлгән гаҗәеп матур манзара тәшкил итә иде. Казан ханлыгы чорында безнең якларда мари халкы яшәгән, моны каберлекләр һәм кайбер атамалар да раслый. Ә инде Казан ханлыгы җимерелгәч, ханлык башкаласы һәм кала тирәсе татарларына Казаннан йөз чакрым ары яшәргә ди- елгән әмергә буйсынып, бирегә татарлар күченеп килгән.

Кенә суы - халыкка гел дә игелек күрсәтә килде. Безнең якта кечкенә елгаларга да су тегермәннәре корылган. Ә менә су ярдәмендә ашлык сугу Анысы безнең авылда гына булган! 1943 ел, сугыш чорының иң авыр елы. Ирләр дә, көчле атлар да — фронтта. Авылда ачлыктан кешеләр терлекләр үлә. Урып-җыю эшләрен башкарып чыгарга, фронтка *икмәк* озатырга кирәк. Сугу машинасын әйләндерү өчен хәлле атлар юк дәрәҗәсендә. “Марс” колхозы реисе инвалид Каюм Хаҗиев уйлап таба җаен: “Су бар! Тегермән ташларын әйләндерүче су сугу машинасы барабанын да әйләндерергә тиеш!” — ди ул. Авылда булган барлык кул көче белән Кенә суын ике яры биегрәк урыннан бөяп, сулык хәзерлиләр. Биектән төшкән су агымы чарыкларны әйләндерә, ул әйләнү хәрәкәте сугу машинасы барабанына кучә. Кыскасы, алты ат һәм ат куучы өч малайның эшен су белән алмаштыралар. Бу искиткеч зур ярдәм була. Су әвене әле сугыштан соң да берничә ел эшләде.

...Җәй көннәрендә безнең авылның тау асты сукмагыннан пөхтә, чиста киенгән төенчекле матур әбиләр үтеп йөргән. Алар - безнең авылдан өч-дүрт чакрым ераклыктагы, хәзерге исеме **Хотня булган авылның изге чишмәсенә** баручы һәм кайтучылар. Авыл

тарихын өйрәнгәндә Хотня авылы һәм әлеге чишмә турында да хик- мәтле риваятьләр ишетергә туры килде.

Изге чишмә борынгы татар зираты эченнән тибеп чыккан. Унтугызынчы гасыр башында чишмәле үзәнлек Петр Алексеевич Перцов дигән кешенең җир биләмәсенә әйләнә. Аны безнең авыл халкы “Алпавыт Перцов” дип йөртә. Алпавытның крестьяннары Чистай өязеннән күчерелгән кешеләр була. Безнең Кенәбаштан да барып ялланып эшләгәннәр анда. 1830 елда салынган чиркәүнең стеналары, колонналы фасады хәзергәчә сакланган. Алар гыйбадәт йортының заманында мәһабәт бина булуын раслыйлар. Чиркәү янында ук Перцовлар токымының каберлеге дә бар. Каберлектәге ташлар, истәлек язулары укырлык хәлдә. Перцовның йорты, серле чишмәле бакчасы борынгы авылның зираты , өстенә салынган. Ташлар арасыннан шаулап аккан мул сулы чишмә алпавыт Перцовның күңеленә хуш килгәндер, әмма ул аның тарихы белән кызыксынмаган. Алай гына да түгел, хатын-кыз һәм әбиләрнең чишмәгә килеп йөрүләре, анда бит-кулларын юып, дога кылып утырулары, дәва өчен суын да савытларга тутырып алып китүләре алпавытка ошамаган. Чишмәгә йөрүчеләрне туктату өчен ул аны күмдергән. Бу эшне башкаручының бер аягы йөрмәс хәлгә килгән, әмма авыруның сәбәбенә төшенүче булмаган.

Шуннан соң көннәр, еллар үтә... Перцовның үз кызы авырый башлый. Табиблар ярдәм итә алмагач, багучыга баралар. Багучы авыруның хикмәте изге чишмә язмышына бәйле булуын аңлатып, чишмәне халык рәхмәтен алырлык итеп, әвәлге хәленә китерергә киңәш бирә. Чыннан да, чишмәне чистарталар, өстен кирпеч корылмалар белән каплап, суын улак аша җибәрәләр. Мин белгәндә һәм бүгенге көндә дә изге чишмәнең суын шифалы дип саныйлар, чишмә янына барып, суын эчеп, дога кылып кайталар. Статист Износков китабында бу чишмә искә алына.

Әйе, тау-ташлар аша, җирнең төрле катламнарын үтеп, җир өстенә чыккан су — безнең көнкүрешебез ихтыяҗла- рын канәгатьләндерүче гап-гади су, ә чынлап торып уйлаганда, тереклеге- безне тәэмин иткән бәһаләп бетерге- сез кыйммәтле су — әлбәттә, изге.

Чишмәләрне карап торучылар, Аллаһы Тәгаләнең савабына лаек рәх- мәтле җаннар булган һәм алар хәзер дә бар, шөкер. Мин яшәгән Карадуган авылы тирәсендә тәмле сулы чишмәләр ага, тик алар халык яши торган урыннан еракта иде. Үзәге шушы авылда булган колхозның рәисе Камил әфәнде Сөләйманов беркем дә уйламаганда зур саваплы эш эшләде - тау буендагы чишмәне торбалар белен авылның нәкъ уртасына китерде. Мең шөкер, менә инде кырык елга якын чишмә авыл халкына зур нигъмәт булып туктаусыз агып тора. Матур итеп эшләнгән зур ак самовардан, чәй эчкәндәй, тәмле су эчәсең, кирәк икән савытлар белән өеңә аласың. Әйе, Балтач район үзәгеннән машина белән килеп, ир-егетләр гаиләләренә җитәрлек тәмле су алып китәләр. Игелеге өчен дога кылып, Кариле авылы кешесе Камил Гаптелгани улы рухына ирешеп торсын, урыны җәннәттә булсын, диябез.

2007 елның көзендә Карадуган мәктәбе укучылары тагын бер тәмле сулы чишмә таптылар. Мәктәп директоры Гөлнара ханым һәм биология укытучысы Тәбрис абыйлары җитәкчелегендә укытучылар һәм укучылар чишмәнең агу юлын асфальт юл буена кадәр китерделәр. Чишмә яны гаҗәп матур суының химик составы турында бе- лешмәсе язылган, утырып ял итү өчен өстәл-урындыклары куелган, гөлләре чәчәктә! Бу чишмәгә “Тәбрис чишмәсе” дип куштылар. Чишмә ачу тантанасында укучылар белән бергә авыл халкы да катнашты. Яңа чишмә мул сулы, җир астыннан сузылган торбалар белен мәктәп янындагы бик матур күлгә кадәр китерелде. Күл суы хәзер чишмә суы белән баетылды, “савыктырылды”, чөнки торбалар ярдәмендә агып чыгу юлы да эшләнде. Ә бу күлне беренчеләрдән булып табигый хәлендә булсын өчен туктаусыз хезмәт куючы хөрмәтенә “Бакый күле” дип йөртәләр. Беренче- яңалык дөньяга икеләнү-шикләр аша килә. “Бакый ага казыта нинди күл булыр... бака күле булып кына калмасмы?” дигән фикер дә булган иде. Ә хәзер авылның иң күркәм җирендә һәр теләүче рәхәтләнеп су коена, балык тотып ял итә торган күл җәйрәп ята. Тирәсендә миләш, шомырт, каен агачлары, күңелләрне һушландырып, су өсте җиләсле ген авылга бөркеп тора.

Карадуганнан Түбән Шубан авылына барганда тау кисеп салынган асфальт юлдан аста җырлап агучы чишмәләр янына туктап алырга онытмагыз. Бу юлдан җәяү үтсәгез, узегезне табигать баласы итеп хис итәрсез Чикләвек куагы һәм имәннәр шәе артыш һәм җир җиләкләренең хуш исе, челтерәп аккан чишмә тавы бөтен деньяңны оныттырып, җаныңны

иркәләр. Инде иелеп чишмәдә бит- күзең юсаң һәм дә бер йотым гына булса да суыннан авыз итсәң, дөньяң тагын да матурланыр, киңәер. Ул суларның серен, сихри көчен белүче аларны саклау эшенә гомерен багышлаган мәрхүм Бәдгытдин бабай чишмәләрнең дәвалау үзенчәлеген белә иде. Аның сөйләвенчә, бер-берсенә якын ук тибеп чыккан ике чишмәнең икесе дә кыйблага таба ага - “Ике күз” чишмәсе. Бу — Бәдгытдин бабай кушкан исем. Ике чишмәнең суы, кушып файдаланганда, күзләргә дә, җан пошуларны да дәвалый икән.

И-и-и, серле дә син Җир-ана. Узган елгы яз айлары, җәй башы күпләрне уйландыргандыр... Ике айга яңгырның тамчысы таммады. Агачлар яфрак яра алмады, үлән тамырлары кипте. Ә аннары су шифасына тиенген табигать бәндәләренә илаһи көч, матурлык, байлык бар итте... Уйланмаслык та түгел шул...

**Мәдинә ЗЫЯТДИНОВА.Балтач районы, Карадуган авылы . Сөембикә // 2009.- №5.- 30-31 бит.**

# УЛАКЛЫ ЧИШМӘЛӘР ТӘМЕ

Туган **авылым Иске Кишет** чишмәләргә бик тә бай. Су өйләргә кергән булса да, күбебез чишмәгә йөри, ашка, чәйгә суны чишмәдән алып кайта. Ни әйтсәң дә – чишмә суы ... тәме дә икенче.

Авылыбызга кергәндә үк Кучы күпере бар. Шул күпернең сул ягында элек чишмә булган, аны төрлечә атап йөрткәннәр. Ә без **Кучы чишмәсе** дибез. Бу чишмә- не Гарифулла дигән кеше карап, чистартып торган. Ни сәбәптәндер ул еллар узу белән томаланган.

Авылдашыбыз сөйләвенә Караганда, Факия апа Шакированың ире Рәүф 1973 елны, якын-тирәдә генә бүтән чишмә булмаганлыктан, күршесе Абдулла белән. бергәләшеп, элеккеге чишмә урынын чамалап, икенче чишмә казыганнар. Ул да юшкынсыз, бик тәмле сулы булып чыккан. Тора-бара аны буралап, ишекләр ясап куялар.

Хәйран гына еллар бу чишмә онытылыбрак торды, суы да кимеде. Шушы тирәнең ирләре бергәләшеп, җиң сызганып, кабаттан чишмәне торгыздылар, яңарттылар. Алар аны буралап, яна такталардан идәнен җәеп, ак калайдан түбәсен ябып, су агу юлларын такталар белән каплап куйдылар. Хәтта чишмәнең өе дә бар.
“Кучы чишмәсеннән аз гына өстәрәк балык буасы бар иде, - дип искә ала Факия апа. - Авыл халкы кәзләп кисеп, шулардан буа буа иде. Елгаларның яры тулып тора. Буага арыклар куйгач, артык суы шуннан ага башлады. Малайлар көймәдә йөзде, балык тотты”.

**Кара үгез чишмәсе** турында бик күп сүзләр йөри. Кайчандыр бу чишмәдә бер байның үгезе батып үлгән. Күрәсең, чишмәнең дә исеме шуннан килә.
Элек ул бик зур, улаклы чишмә булган. Зур-зур тагаракларда ашлык юганнар, тау башына алып менеп киптергәннәр. Кара үгез чишмәсенен суы «тота», аның суына сокланырга ярамый, дип сөйлиләр. Бу чишмә турында тагын шундый риваять тә йөри: әгәр дә аның юлында яткан ташны кузгатсаң, тирә-юньне су баса, имеш.

Елга буйлап тагын да өскәрәк менүгә, **Ташчишмәгә** юлыгасың. Аның стеналары таш белән әйләндереп куелган, исеме дә, бәлки, шуннандыр. Элек монда хуҗалыкның җәйләве булган. Сыерларны шул җәйләүдә сауганнар, малларга су эчергәннәр.
Кучы елгасының башлангыч урыны да шушы Ташчишмәдән, аңа Кара үгез һәм башка вак чишмәләр кушылып, җыйнак кына Кучы елгасын хасил итәләр, ә ул үз чиратында Симет елгасына коя.

Авылыбызның урта бер тирәсендәрәк, Симет елгасы аша зур күпер салынган. Аны чыккач, сул якта тешләренне камаштырырлык чиста, салкын, искиткеч тәмле, саф сулы **Улак чишмәбез** агып ята. Бу чишмәнен суы шифалы. Аны ерактан кайткан кешеләр үзләре белән дә алып китәләр. Туган авылларын сагынып кайтканнар утырып дога кылалар. Чишмә тирәсе зур һәм ул койма белән әйләндереп алынган. Чишмә әйләнәсендә элек тополь агачлары үсә иде, аны Кыям мулла утырткан булган. Ул агачлар колач җитмәслек юан, биек булып үсеп, тирә-юньгә куркыныч тудыргач, аларны кистерделәр һәм ул урынга өмә ясап, мәктәп укучылары яшь үсентеләр утырттылар. Хәзер ул агачлар матур булып үсеп килә. Әлбәттә, чишмәнең, еллар узу белән, суы кимеде, аның улакларын да алыштырырга кирәк. Ә бу эшкә тотыну зур чыгымнар таләп итә. Спонсорсыз һич була торган түгел. Ярый әле, инициативаны Иске Кишет авылыннан чыккан, Арчада яшәп, нефтебазада эшләүче Габделфәт Ситдыйков үз кулына алды. Хәзер чишмәбезнең өсте ябулы, полиэтилен торбалардан ургылып аккан суга карап куанабыз.

Улаклы чишмәне үтеп, каенлык ягына борылгач, Иске Зират чишмәсенә тап булабыз. Чишмәнең дүрт почмагында дүрт тал агачы үсеп утыра. Ул агачларны Җиһанша исемле кеше утырткан. Әле дә хәтеремдә, без кечкенә чакта әбием Бибисара белән еш кына Яңа Мәңгәргә менә идек, чөнки без элек шул авылда яшәдек, әбием дә килен булып Яңа Мәңгәргә килгән, шунда ирен сугышка озаткан, балалар үстергән, аларның һәркайсын башлы-күзле иткән. Шуңадырмы, аның күңеле һәрчак Яңа Мәңгәргә тартыла иде. Җәйнең эссе көннәре булса, без шул Иске Зират чишмәсендә тукталып, бит-кулларыбызны юабыз, тәмләп су эчәбез, анда һәрвакыт су эчәргә стакан, кружка булыр. Чишмә рәшәткә белән әйләндереп алынган, гел караулы.

Әбием утырып дога кыла һәм киемнәребездән берәр җеп өзеп, суга сала, янәсе, су безне «тотмасын», шул җепне «тотсын». Бүген чишмәнең дүрт ягында дүрт тимер багана, багана очларында ай балкып тора.

Соңрак чишмәнең өстенә тимердән бик матур итеп кечкенә генә өй дә ясап куйдылар. Бу изге эшне авылыбызның тырыш, мәртәбәле кешесе Вәкил абый Әскәров башкарды.

Елга буйлап бара торгач, Шөгале чишмәсенә дә килеп җитрбез.
Кайчандыр авылдашыбыз Индус абый Гобәйдуллинның үзе ясаган чишмәсе дә шаулап ага иде.

Хәзерге көндә чишмә җимерек хәлдә, ул урында яр бик каты ишелде. Элек шул чишмәдән су алып кайта идек, керләр чайкау өчен дә бик уңайлы иде. Ә чишмәнең тарихына килгәндә... 1989 елны Индус абый үзләре өчен дип, кое казый. Су фонтан булып бәреп чыга. Нишләргә? Индус абый полиэтилен торба сатып ала һәм коега шул полиэтилен торбаны ялгап, җир астыннан елга ярына хәтле суза. Аларга инеш якын гына. Шулай итеп, Индус чишмәсе дөньяга килә. Бу чишмәдән бик күп еллар күпме кеше файдаланды. Колонкаларда су беткәндә, авылның Мәңгәр очы халкы шунда суга бара иде.

Берничә ел элек Индус абыйларның күршеләре Шамил абый да чишмә «тапты». Елга ярында полиэтилен торбадан чишмә агып ята иде. Шамил абый аңа баскычлар, басмалар ясап куйды. Агымы бик көчле, суы да тәмле, ә иң мөһиме - юшкыны аз. Бу чишмәдән дә халык файдалана. Һәркемнең өендә су, ә халык чишмәгә бара. Кыш көннәрендә Шамил абый чишмәсен карап, бозларын чабып, карларын көрәп, баскычлар ясап куя.

Иске Кишет авылында болардан тыш та чишмәләр бик күп, әйтик, **Күләй, Чәләнгеч чишмәләре**... Аларны гел карап, чистартып торганда гына авыл тарихы сакланып калыр.

**Гөлфия Габитова**. **УЛАКЛЫ ЧИШМӘЛӘР ТӘМЕ // Сөембикә.- 2009.- №6.-56-57 бит.**

## Курса почмак чишмәләре

Һәр авылның үз яме, курке бар. Безнең **Курса Почмак** мул сулы чишмәләргә бай булуы белән аерылып тора.

Халык чишмәләргә ягымлы, матур, җисеменә туры килә торган исемнәр дә кушкан. Авылымның **Ишимбай, Факия, Сәйфи, Шаһи, Фоат, Галиулла, Хатирә, Хәмит чишмәләре** шундыйлардан.

Дөрес, хәзер чишмә юлларын таптаучылар көннән-көн азая бара, чөнки керне машина юа, су краннан агып тора... Ләкин шулай да авыл халкы чишмәләрне онытып бетерми, чөнки алар су чыганагы гына тугел, ж,ан тынычлыгы бирүче ял урыны да.

Гает һәм Корбан бәйрәмнәре көнендә авылымның күп кенә кызлары, киленнәре, ир-атлар мәчеттә булганда, чишмә суы алып менәләр. Күрше-тирәдәге ялгыз әби-бабайларны да онытмыйлар. Гадәт буенча, чишмәгә төшкәндә- менгәндә теләкләр теләнә һәм бу көндә чишмә юлында теләнгән теләкләр кабул була дигән ышану да бар.

Без, мәктәп укучылары да, чишмә тирәләрен гел җыештырабыз, өмәләр үткәрәбез.
Хәзер чишмәләрне яңарту, бизәү дә гадәткә кереп бара. Бу елларда, мәсәлән, авылдашыбыз Рүзил абый Мотыйгуллин җитәкчелегендә **Ишимбай чишмәсе** яңартылды. Ул хәзер үтеп барган һәр кешене үзенә чакырып тора.

Безнең авылның чишмә сулары әле илһам чыганагы да. Шагыйрә Сания Әхмәтҗанова, Татарстанның халык артисты, җырчы Шамил Әхмәтҗанов, цирк артисты Ильяс Халиков, Г. Камал театры артисты Фәнис Җиһаншалар безнең чишмә суларын эчеп үскән.

**Энҗе Сөләйманова.Арча, Курса Почмак. Сабантуй // 2011.- №6.- 5 февраль.- 3 бит.**

## Хисми чишмәсенең яшьлеге

— Сабантуйга да бу кадәр халык җыелмаган иде. Күр әле, нинди күңелле! Уены-җыры дисеңме! Ул биючеләрне әйт! Чәй белән коймагына кадәр әзерләткәннәр бит, — авыл хапкы **Чишмә бәйрәмен** оештыручыларга әнә шулай рәхмәт укыды.
Бер яктан яшен уйнатып, күкрәп, кара-кучкыл яңгыр болыты килә, икенче яктан таң яктысы беленә. Ә **Югары Курсаның** үзәк урамында, тау битендә бәйрәм гөрли. Аңа Урта Курса, Түбән Курса, Корайван, Сарай Чокырча, Курса Почмак, Иске Му, Сикертәннән дә килгәннәр. Район мәдәният йорты директоры Булат Гайнуллин (Югары Курса егете!) иң оста һәвәскәрләрне җыеп кайтып авылдашларын сөендерде. Биюче Гөлнара Кадыйрова, җырчы Равил Габдрахманов, Сәрия Усмановалар чыгышын «Аулак өй» күренеше алыштыра. Чишмәне исә Югары Курсада туып-үсеп, бүген «Водоканал» оешмасында инженер булып эшләүче Дамир Хәбибуллин хәләл хезмәт хакына төзекләндергән. Шуңа да Дамирның сыйныф җитәкчесе Зөбәрҗәт Галләмованың шатлыгы эченә сыймый:
— **Хисми чишмәсен** яңадан эшлиләр дигәнне ишеткәч бер сөенсәм, Дамир эшләтүен белгәч шатлыгымнын чиге булмады, — диде ул.
Хисми чишмәсенең тарихын да халыкка укытучы сөйләп бирде:
— Хисмәтулла чишмә чыккан яр өстендәге урамда яшәгән. Яр буйлап бәреп чыккан чишмәләр бик күп була. Хисми абый менә шуларның берсен казып, һәркем килеп су алырлык чыганак ясый. Улы Шәймулланың уз баласы булмагач, Исрафил исемле малайны тәрбиягә алып устерәләр. Хисми абый нигезендә хәзер Исрафилның улы Ирек хатыны Зөлфия белән яши, изге нигездә балалар үстерделәр.
...Авыл халкы Чишмә бәйрәмен ел саен уздырырга булды. Яшәгән урынны матур, төзек итеп тотарга кирәклеге хакында искә төшереп тору өчен.

**Чулпан ГАТАУЛЛИНА,**
Югары Курса, Арча районы. **Хисми чишмәсенең яшьлеге // Мәгърифәт.- 2007.- №33.- 18 август.- 6 бит.**

# Туган ягымда

"Тау астыннан чишмә ага. челтер-челтер тавышы..." Бу шигыырь юллары минем туган ягым - Арча районындагы **Кысна авылындагы "Улаклы чишмә"гә** атап чыгарылган диярсең. Як-ягына шомырт, миләш, чия агачлары үскән сукмакган тау астына төшсәң, яр кырыеннан ургылып аккан "Улаклы чшнмә"гә килеп чыгасың. Чишмә яныннан бик матур болын җәелеп китә. Якында гына - "Ләйлә" аланы. Җәй көннәрендә болын һәм алан аллы-гөлле чәчәкләргә күмелә. Агачларга кунып сандугачлар сайрый. Халык медицинасында мактала торган мәтрүшкә, меңъяфрак, каен җиләге шул болын- аланнарда үсә дә инде. Ә чишмәнең суы искиткеч шифалы да, тәмле дә.

Бу чишмә суын тирә- күрше авыл кешеләре, шәһәрдән кайткан кунаклар да зур шешәләргә тутырып алып китә. "Улаклы чишмә" суы дәвалау үзлегенә ия, күрәсең. Күрше авылдагы параличланып урын өстендә яткан бер апа: "Улаклы чишмә" суын эчсәм, терелермен күк, дигәч, уллары шул чишмәдән су алып кайтып эчерәләр. Хо- дайның рәхмәте, бу апа әкренләп аягына баса, йөреп китә, балаларына бик рәхмәтле була.

Бабам чишмәне карап, тәрбияләп тора. Кыш көннәрендә сукмакларын көри, баскычлар ясый. Бабам: "Их, бу чишмә суын шәһәр кешеләренә эчертеп торыр идем", - ди.

**Алинә Габделхакова, КДУ студенты . Туган ягымда // Ватаным Татарстан.- 2009.- № 153.- 29 июль.- 4 бит.**

# Суга сусаган - чишмә чистарткан

Белүебезчә, 2013 ел - Экологик культура һем әйләнә-тире мохитне саклау елы дип игълан ителде. Әлбәттө, бу юкка гына түгел. Тирә-юньгә куз салуга, безне чолгап алган мохитнең пычраклыгы, чүп-чары күзгә ташлана. Бу - халыкның экологик яктан культурасызлыгы билгесе.

Миңа Аурупаның күп илләрендә булырга туры килде. Әйтик, Финляндиягә автобуста барган вакытта, Ленинград өлкәсендәге юл буе чүп-чар белән тулган иде, ә инде Финляндия территориясенә килеп кергәч, тирә-юньнең чип-чиста булуына га- җәпләндем. Димәк, биредә халык экологик яктан культуралы. Ә моңа ничек ирешергә соң? Административ чаралар кулланырга, диярсез. Әлбәттә, моның роле бар, ләкин файдасы аз булачак. Ягъни төп культура чарасы - халыкка тирә-юньне пычраткан өчен штраф салу гына түгел, ә бәлки, гаиләдә, балалар бакчасында, мәктәптә даими рәвештә үткәрелә торган экология тәрбиясендә.

Кешелек дөньясының хәзерге үсеш этабы табигать белән җәмгыять арасындагы тирән каршылыклардан тора һәм шуның нигезендә тирән социаль-экологик кризисы барлыкка килде. Әйләнә-тирә мохит кискен үзгәреш кичерә, ул химик, физик элементлар белән пычрана, туфракның продуктлылыгы һәм уңдырышлылыгы нык түбәнәя, ашамлык-ризыкларның сыйфаты начарая бара. Кешелек җәмгыяте һөм та- бигать арасындагы үзара мөнәсөбәтләрнең бозылуы бик күп санда үсемлекләр һәм хайваннар дөньясының юкка чыгуына китерә. Шуның нәтиҗәсе буларак, кешенең иммун системасы какшый, нөселдәнлек үзгәрә, аның авыруларга каршы торучанлыгы кими бара.

Кешелек дөньясының үз-узен юкка чыгара баруы җәмгыять, мәктәп һәм педагогика фәне алдына кичектергесез бурыч куйды. Ул - бүгенге һәм киләчәк буын уку- чыларында, яшьләрдә экология культурасы тәрбияләүдән гыйбарәт.

Татар халкының авыз иҗаты безгә экологик тәрбия мирасын бүгенге көнгә чаклы ук алып килгән. Без аларны мәкальләрдә, әйтемнәрдә, табышмакларда, сынамышларда, легендаларда, җырларда, бәетләрдә, мифларда, мөнәҗәтләрдә һ.б.

очратабыз. Шулай итеп, халыкның педагогика һәм экология белемнәре безгә килеп җиткән, шул ук вакытта алар бүген дә үз кыйммәтлерен югалтмыйча, яшь буында экология культурасын формалаштыруда төп нигез булып тора.

Халык бик борынгы заманнан бирле игенчелек белән шөгыльләнгән һәм аның максаты, табигать кануннарына нигезләнеп, җирне акыл белән эшкәртү булган. Тормыш итү дәверендә ул табигать һәм андагы компонентларның үзара бәйләнеше турында гаять зур белемнәр туплаган һәм аларны тормышта даими кулланган. Элек “экология” тешенчәсен, гомумән, белмәгәннәр, ләкин халыкның бай тормыш тежрибәсенә нигезләнгән экология белемнәренә ия булуы хакында гарәп, урыс һәм башка халык вәкилләре, сәяхәтчеләре, галимнәре язып калдырган. Тарихи-этнографик материаллар нигезендә, безгә шунысы мәгълүм: татар халкы табигый мохит белән тыгыз бәйләнештә яшәгән. Татар халкының озын-озак тарихы, бик иртә дәүләт коруы, аның тормышында экология культурасы югары булуы хакында сөйли.

Татар халкының табигать педагогикасы һәм экология турындагы белемнәре хәзинәсен асылда авыл җирендә яшәүче әбиләр һем бабайлар саклый. Шунысы кызганыч, әле бүген дә гомуми белем бирү мәктәпләрендә, гимназия, лицей, институт һәм университетларда халыкның экология белемнәрен, традицияләрен, гореф-гадәт ләрен тормышта куллануга әлләни зур әһәмият бирелми.

Элек-электән авылда яшәүче һәр кеше укый-яза белмәсә дә, табигать телен яхшы аңлаган, күзәтүләр нигезендә табигатьнең серләрен ачыклый алган. Бу белемнәр атадан балага, бер буыннан икенче буынга мирас булып күчкән. Берничә дистә еллар буе, күп кенә милли традицияләрнең юкка чыгуы белән беррәттән, халык эколо- гиясенә карата да игьтибар кимеде, ә бу инде, үз чиратында, табигатькә кеше тара- фыннан тискәре йогынтының артуына китерде. Әйткәнемчә, табигать турындагы белемнәр халык авыз иҗатында киң чагылыш тапкан. Кыска, ләкин хикмәтле сүзе

белән халык тирән мәгънәле фикерләрен бер буыннан икенче буынга җиткергән. Шуңа күрә дә аларны «ата-баба» сузе, диләр. «Җилгә каршы төкермә, сузең җилгә китәчәк», «Туфракны җир иткән - изгелек күргән, җирне туфрак иткән - ачтан үлгән», «Кәкре агачны төзәтүдән, тез агачны кәкрәйтү җиңел», «Суга сусаган - чишмә чистарткан», «Урман утырткан - ачлык

күрмәс», «Коега төкермә, суын узең эчәрсең», «Җ,ир яктысы - кояш белән, кеше яктысы - белем белән», «Белем эштән башлана». Менә шундый мәкаль һем әйтемнәр яшь буында игелекле эшләр башкарырга омтылыш уята.
Бала беренче белемнәрне гаиләдә туплый, аннан балалар бакчасында, мәктәптә
ала, аңа әти-әниләре булыша, тирә-юньдәге кешеләр ярдәм итә. Ул шулай ук өстәмә мәгълүматны Интернет челтәреннән эзләп таба. Телевидениенең аерым каналлары да даими ревештә табигать дөньясын күрсәтеп тора.

Кыскасы, мәктәптә туплаган фәнни белемнәрдән тыш, бала халыкның экология белемнәренә дә ия булырга тиеш. Әлеге белемнәрне санга сукмау кешелек җәмгы- ятенә зур зыян китерә. Шундый белемнергә мисал итеп, «Белмичә утыртылган агач тиз корый»,«Кое казыган кешегә су бирмичә ярамый», «Кое кибеп бетмичә, без суның кадерен белмибез», «Эчкән чишмәңә пычрак ташлама», «Пычрак елгада чиста су булмый», «Саф чишмәдән агып чыкса, елга да чиста була», кебек әйтемнерне ките- рергә мөмкин.

Экология культурасының янә бер фәнни нигезе - экологик фикерләү һәм аң. Үз вакытында Һ.Һейне бу хакта болай язган:”Фикер - ул күзгә күренми торган табигать, ә табигать узе - күзгә күренүчән фикер”. Әйе, фикер йөртү – кешенең танып-белү процессында иң югары баскыч. Кеше - ул табигать баласы. Табигать белән берләшкән барлык нерсәләр балада экология культурасы тәрбияләүдә файдаланылырга тиеш. Баланы чолгап алган әйләнә-тирә мохит- ул барыннан да элек күренешлергә чиксез бай гүзәл табигать дөньясы. Табигать - бала акылы үсеше өчен мәңгелек чыганак. Бу хакта күренекле педагог В.Сухомлинский түбәндегечә язган: “Нейроннардагы нерв көченең менә шулай гаҗәеп тизлектә күчеп йөри алуы баланың фикер йөртүе була да инде. Баланың баш мие күзәнәкләре шулкадәр нәфис, үзләштерү объектына шулкадәр сизгер, алар кабул итәргә тиешле объект күреп торырлык, ишетелерлек һем аңа кагылырга мөмкин образ булган очракта гына ул күзәнәкләр нормаль эшли ала». Бала беренче фәнни хакыйкатьне әйләнә- тирә мохиттән алырга, табигать күренешләренең матурлыгы һәм бетмәс-төкәнмәс катлаулылыгы аның өчен фикер чыганагы булып калырга тиеш. Шул нигездә баланы эзлекле рәвештә иҗтимагый мөнәсәбәтләр һәм хезмәт дөньясына алып керерге кирәк.

Укыту һәм тәрбия - бердәм процесс. Фикерләү процессы барлыкка килсен өчен та- бигать белеме һәм гуманитар фәннәрне проблемалы ревештә укытуның әһәмияте гаять зур. Әгәр балага белем алуда һәрнәрсә җиңел бирелсә, аңарда акрынлап фикерләү ялкаулыгы тәрбияләне. Моны булдырмас өчен, проблемалы сораулар кую, проблемалы танып-белү мәсьәләләре һәм тикшеренү характерындагы уку биремнәре бирелә. Иң мөһиме - баланы укыганда уйларга өйрәтергә кирәк. Белем алу процессы белән бергә акыл хезмете культурасы һем дисциплинасы да тәрбияләнә. Балалар нәкъ менә акыл хезмәтендәге авырлыкның ни икәнен сизсен. Бу инде мөһим тәрбия месьәләсе.Укытучы балалар күңелендә танып-белү шатлыгының интеллектуаль хисен уята белә, бик зур уңышка ирешә. Хакыйкатьне ачу, проблемалы укытканда тикшеренү белән бәйле кечкенә генә уңышлар да балага шатлык алып килә. Бу очракта табигать белән турыда туры аралашу кирәк, шуннан башка укучының акыл көче һем нерв энергиясе чишмәсе бик тиз саега. Бары тик табигать дөньясында укучылар җисем һәм күренешлер арасындагы сәбәп-нәтиҗә бәйленешенә игътибар итә, үзара бейләнешләрне ачыклый - болар исә белем алу гына түгел, ә бәлки үз чиратын- да, әһәмиятле тербия чарасы да.

Шулай итеп, белемнәрнең шактый зур өлеше укучыларга әзер килеш бирелми, ә проблемалы ситуация халәтендә аларның үзләре тарафыннан мөстәкыйль танып- белү эшчәнлеге процессында алына,нәтиҗәдә яңа, төпле табигать һем экология белемнәре үзләштерелә. Ф.Дистервег фикеренчә, «Начар укытучы чынбарлыкны үзе ачып бирә, ә яхшы укытучы чынбарлыкны табарга өйрәтә».

Экологик фикерләү ул - кеше һәм табигать арасындагы мөнәсәбәтләрне ачыкла- уда һәм аңлауда фикер йөртүнең иң югары формасы. Фикерләүнең беренче дәресләре класста, класс тактасы янында түгел, ә белки, табигать кочагында үткәрелергә тиеш. Экологик фикерләү нигезендә укучы бала табигатьтәге закончалыкларны, андагы үзара бәйләнешләрне ачыклый, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен хәл итә, аңа әйләнә-тирә мохитне танып-белүдә, аны аңлауда зур этәргеч булып тора. Шулар нигезендә бала акрынлап экология культурасын үзләштерә.

Экологик фикерләү нигезендә балада экологик аң формалаша. Экологик аңның нигезе булып экологик белемнәр һем осталык тора. Безнең уебызча, экологик аң - ул шәхеснең табигый-социаль мохитне идеал рәвештә фикерләү мөмкинчелеге. Ул тойгы, зиһенгә алу, күзаллау, фикерләү һәм хисләрдән тора. Кешенең фикерләве бер үк законга буйсына, шул ук вакытта ул җәмгыятьнең тарихи һөм социаль-икътисади үсеш шартларыннан чыгып, милли төсмере буенча аерылып та тора.

Шулай итеп, шәхеснең аңы аерым бер халыкның этнопедагогикасы, этнопсихологиясе һөм этнокультурасы белән үзара бәйле. Шул сәбәпле, бүгенге көн мәктәбе алдына түбәндәге бурыч куела - мөстәкыйльлеккә ирешкән, әхлакый җит- леккән экологик культуралы шәхес тербияләү. Безнең уебызча, экологик культуралы кеше - ул интеллигент һәм цивилизацияле, фәнни һәм халык экологиясе белемнәрен үзләштереп, экологик яктан фикерләп, эшли, яши һем табигый-социаль мохитне саклый торган шәхес.

Мәктәп укучыларын табигать дөньясы гына түгел, хезмәт, иҗат, тезелеш деньясы да чолгап ала. Кешенең матурлыгы хезметтә тагын да киңрәк ачыла. Татар милли мәктәбендә укучыларның хезмәт чыганагы “өмә” булып санала. Өмә - татар халкында ярдәмләшү йоласы. Халык бу хакта болай ди: “Кешегә игелек итсәң - үзеңә булышасың”, “Кеше турында кайгырткан кеше бәхетле була”. Ул, халык традициял- әре буенча, авыл хуҗалыгында авыр эшләрне (урак уру, печән чабу, утын әзерләү, бура күтәрү) тизрәк тәмамлау, яисә аксакаллар карары нигезендә тол калган хатыннарга, ятимнәргә, йорт-җире янган кешелергә ярдәм итү йезеннән, юлларны, чишмәләрне һ.б. төзекләндерү нияте белән оештырылган. Үз вакытында ул киез басу (тула өмәсе), җеп өрлеү (җеп өмәсе), киндер агарту (киндер өмәсе), каз йолку (каз өмәсе) шикелле уен-җырлы, такмаклы, такмазалы яшьләр бәйрәме буларак үткәрелгән. Халык өмәдә вакытта: “Син эштән курыкма, эш синнән курыксын», - дип, яшь буынны өйрәтә килгән. Ярдәмләшү гадәте татар халкында бүгенгәчә яшәп килә, ул халыкның табигать белән бәйленешле бәйрәм-йолаларында да чагыла һәм укучыларда экология культурасы формалашуга ярдәм итә.

Балаларның уеннары да экология культурасы тәрбияләүгә ярдәм итә. Тарихи яктан Караганда, экологик уеннарны балалар бергә җыелган вакытта башкарган. Бу ва- кытта балалар төрле яшьтәге төркемнәргә берләшкән һәм аларда экологик тертип саклау җайланмасы булган. Мисалга, татар халкының җырлы-биюле күмәк уен җырларын алырга мөмкин. Уен җырлары элек-электән кышкы кояш торышы вакытын (“Нардуган”) каршылаганда, туйда, кич утырганда (“Аулак өй”), яшьләрнең җырлы- биюле уеннары вакытында һәм күмәк хезмәт барышында (“Өмә”) башкарылган. Болар бигрәк тә узган гасырның 30 нчы елларында киң таралган.

Шулардан табигать белән нык бейле булган Нардуган бәйрәменә тукталыйк. Ул төрки-татарларда елның иң кыска көнен билгеләп утү бәйременә - 22 декабрьгә туры килә. Яшьләр үз авыллары янындагы калкулыкка чыгып, учак яккан. Яшь-җилкенчәк, бала-чага кеше танымаслык итеп киенеп, өйдән-өйге йөргән, әйлән-бәйлән һ.б. уеннар белән күңел ачкан, йөзек салып баккан һ.б. Керәшен татарларында Нардуган христиан раштуасы вакытында бәйрәм ителә. Тарихка күз салсак, ул 1651 елдан Нократ татарларында (аларда ул удмуртча “вожо” дип атала) һәм мишәрләрдә (“нардыван”) Яңа ел буларак бәйрәм ителгән. Ул төрле уеннар белән кызларның кич утыруы рәвешендә үткәрелгән.

Шулай итеп, татар халкының табигать белән тыгыз бөйләнешле уеннарын мәктәпләрдә куллану балаларда экологик культура тәрбияләүдә зур ярдәм итә.

Хезерге заманда үзләренең шәхси теләкләренә чик куя белмәгән кешеләр саны арта бара. Бар дөньясы байлыкка мөкиббән киткән, акча иң мөһим нөрсә итеп санала. Ләкин шуны онытмыйк: «Һәлак булыйм дисәң, йә мал тупла, йә надан кал», - ди халкыбыз. Шунысы мәгълүм, кеше үзенең шәхси мәнфәгатьләренә чик куя алмый икән, ул беркайчан да яхшы кеше була алмый. Үз- үзләрен яратучылар, үз файдалары өчен генә тырышучылар, кеше кайгысына һәм уңышсызлыгына шатланып, аңа ваемсыз караучылар, нәкь менә бала чакларында үз теләкпәрен генә үтәтеп, аларны барыннан да өстен куеп, башкаларга битараф булганнар арасыннан килеп чыга да инде.

Соңгы елларда мәктәпләрдә бәйләнчек, әдәпсез балалар күбәйде, дибез. Бу инде балаларда була торган индивидуализмның бер чире. Әгәр ата-ана баланың хилаф эш-

ләрен гафу итсә, ул җәзасыз калуга шатланып, укытучыга һәм башкаларга карата дорфа мөнәсәбәттә була, аларның сүзен тыңламый башлый, ә соңыннан үз ата-анасына да көн күрсәтми. Нәтиҗәдә әхлаксыз буын барлыкка килә. Әхлаксыз буын балалары да шундый ук тәрбия ала һәм җәмгыять рухи яктан таркала. Бу - бик куркыныч күренеш. Күренекле философ И.Кант: «Тәрбия сәнгатенең принципы шундый: балалар бүген өчен тәрбия алырга тиеш түгел, ә бәлки, алар киләчәк буын кешелек дөньясының та-гын да яхшырак сыйфатын тудыру өчен тәрбия алырга тиеш», - дип язган.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: кеше кайгысына һәм газапларына карата сизгер һәм ярдәмчел булу сыйфатлары тәрбияләү мәктәпнең һәм гаиләнең гомуми бурычы. Бүтән кешенең кайгысын үз кайгысы итеп санаганда гына кеше башка берәүгә дус, иптәш һәм туган була ала. Шуңа күрә балага тәрбия биргәндә, тәрбиячеләр шуны онытмасын: бала икенче бер кешене йөрәге, хисләре белән тоярга тиеш. Шунсыз ул беркайчан да чын кеше була алмый. Тоярга, хис итәргә өйрәтү - мәктәптә дә, гаиләдә дә иң читене. Шәфкатьлелек, сизгерлек, ярдәмчеллек, кайгы һәм шатлыкларны уртаклашу гаилә һәм мәктәпнең бердәм тәрбия системасында гына тормышка аша ала. Әгәр гаиләдә баланың ата-анасын, әби-бабасын ихтирам итү хисе аларга игелек эшләү теләге белән ныгытылмаса, ул эгоистик хискә әйләнә. Бала әти-әнисен үзенә шатлык тудыру чыганагы булганы өчен генә ярата. Башкалар язмышы өчен борчылу, дулкынлану, кайгырту, газаплану хисләре тәрбияләгәндә генә бала йөрәгендә чын кешелек сыйфатлары тууын онытмаска кирәк.

Шулай итеп, балачакта кеше гомуми мәктәп белән бергә эмоциональ мәктәпне матур хисләр тербияләү мәктәбен дә төгәлләргә тиеш. Шуңа күрә бала акыллы һәм зирәк булсын өчен аны яшьтән үк табигать дөньясына алып керергә кирәк.

Бала тәрбияләүдә шәфкатьлелекнең ролен күрсәтеп, күренекле педагог Я. Корчак болай язып калдырган: «Балаларның керсез саф демократизмы дәрәҗә аерымлыгын белми. Ялчының түккән тире һәм аның ач- ялангач яшьтәше, атның авыр язмышы һәм чалынган тавыкның әҗәле баланы вакытыннан элек кайгыга сала. Аңа эт тә, кош та якын, аның өчен күбәләк белән чәчәк икесе дә бер, вак ташны да, әкәм-төкәмне дә ул үзенең туганы итеп саный. Үзен күрсәтергә тырышу тәкәбберлегеннән азат бала рухи- ятнең бары тик кешедә генә булуын белми».

Халыкның экология педагогикасы чаралары балаларда экология культурасы формалаштыруда әһәмиятле фактор булып тора. Халык авыз иҗаты - мәкальләр, әйтемнәр, табышмаклар, легендалар, әкиятләр, җырлар һ.б. буыннан-буынга күчеп килгән. Укытучы аларны дәрестә һәм дәрестән тыш чараларда кулланганда, укучылар күз алдына халыкның экологик эшчәнлеге һәм табигатьне саклау чарапарыннан торган образлар туа.

Әйтик, безнең халык элек-электән чишмәләргә бик игътибарлы булган. Борынгы Биләр шәһәре янында Хуҗалар тавы бар. Биредә ничәмә-ничә гасырлар буена борынгы бабайлар саклаган, чистарткан, аңа сокланып караган Изгеләр чишмәсе ага. Халыкның элек-электән чишмә-суларга карата шундый игътибары әйләнә-тирә мохит- не табигый хәлдә сакларга мөмкинлек биргән, нәтиҗәдә экология системасының тотрыклы яшәеше сакланган.

Аксубай районы, Иске Үзи авылы туфрагында да легендар Тырышмал чишмәсе бар. Халык бу чишмәне дә Изге чишмә дип атый, аның янына гыйбадәт кылырга килә, көмештәй саф суыннан файдалана. Изге чишмәне халык кадерли, саклый, карап, тәрбияләп тора. Чишмә янында күңелне тетрәндерә торган һәйкәл дә бар. Ул 1236 елда Мәрҗән каласын илбасарлардан саклаганда шаһит киткәннәр истәлегенә торгызыл- ган. Бирегә килгән һәр бала аның алдында түкталып, озаклап басып тора, уйлана, та- рихны исәе ала. Изге чишмә тирәсе зәвыкле, сәнгатьле итеп бизәлгән, ягъни аның ба- лаларга эстетик тербия бирүдә дә әһәмияте бар.

Хәер, безнең тебәктә яшәүче башка халыкларның авыз иҗатында да суга багышланган экология белемнәре киң чагылыш таба. Урыс халкы бу турыда болай ди: «Плевать на воду - все равно, что матери в глаза» - «Суга төкерү - үз әниеңнең күзенә төкерү белән бер». Чуаш халкында: «Таса салкусран тара тыв юхать» - «Чиста чишмәдән чиста су ага» дигән әйтем бар.

Фольклорның кече жанрлары арасында сынамышлар үзенчәлекле урын тота. Алар киләчәктә һава торышының, ашлык, яшелчә, җиләк-җимеш уңышының ничек булачагы хакында алдан ук хәбәр бирү максатына хезмәт итә. Һава торышын алдан әйтү өчен табигать

дөньясындагы күп төрле билгеләр һәм күренешләр нигез итеп алына. Әйтик, күк җисемнәренең ничек күренүе, хайваннар, кош-кортларның үз-үзләрен тотышы, ел фасылларының, халык календаренда әһәмиятле саналган аерым көннәрнең ничек килүе һ.б. Кыскасы, сынамышлар халыкның гасырлар буена туплый килгән гамәли тәҗрибәсе, кат-кат сынау-күзәтүләре нигезендә туган. Мәсәлән: «Йолдыз тирәсендә кара алка булса, яңгыр булыр», «Йолдызлар тирәсендә кара түгәрәкләр күренсә, яңгыр галәмәте»,«Ж,илгә каршы яуган яңгыр каты давыллы булыр», «Кар барында күк күкрәсә, ашлык булмас» һ. б.

Сынамышларга ышанулар якын тора. Алар да алда нәрсәдер булачагын хәбәр итү, юрау өчен әйтелә. Ләкин ышанулар сынамыш кебек тормышны күзәтүгә, тәҗрибәгә түгел, бәлки, хорафатка корылган..

Ышанулар киләчәкне юраганда барысын да ал да гөл итеп кенә күрсәтми. Алар арасында ниндидер хевеф-хәтәр, бәла-каза килү ихтималын искәртә торганнары да бай- так. Боларына сукырларча ышану кешене хафага салырга, хәтта аның тормышын фаҗигагә алып барырга да мөмкин. Бүгенге күзлектән чыгып Караганда, мондый ышануларның мәгънәсезлеген һем зарарын аңлау кыен түгел. Хәлбуки, халык үз вакытында алар ярдәмендә кешеләрне сизгерлеккә, уяулыкка, сакланып, уйлап эш итәргә өйрәтү максатын да күздә тоткан булырга тиеш. Гомумән, ышанулар халыкның экология педагогикасында әһәмиятле урын алып тора. Яшь буында үз-үзеңне матур итеп тота белү, чисталык, пакьлек, ашау-эчү әдәбе һәм башка күркәм күнекмәләр тәрбияләүдә халык ышанулардан киң файдаланган. Мәсәлән, күренекле урыс язучысы, этнограф В.Даль болай дип язган: «Бары тик зур игелеккә ия булган, талантлы халык олы рухи көч туплаган. Юмор хисен ул теләсә нинди авыр шартларда да югалтмаган. Табышмаклар, әйтемнәр, такмазалар халык иҗатында туып, аның көчле организм булуы хакында сөйли”.

Кыскасы, мәкаль һәм әйтемнәрдән торган экология педагогикасы чаралары халыкның табигатькә карашын, әхлакый-эстетик фикерен, тарихи-социаль үсеш үзенчәлекләрен ачыклый, яшь буынга табигатьне саклауның төп юнәлешен ачып бирә.

Дини экология культурасы Ислам дине татар халкының экология культурасын формалаштыруда әһәмиятле урын били. Бу хакта галим К.Дәүләтшин болай дип яза: «Халыкның милли аңын үстерүдә Ислам катнашмады, дип раслау дөрес булмас иде. Ул милли аң белән тыгыз бәйләнгән һәм үрелгән». Ислам культурасының асылы Коръән принципларында киң чагыла.

Мәсәлән, өлкәннәр Коръән буенча яшь буынны элек-электән шулай өйрәтеп килгән: “Җирдә бәхетсезлек таратмагыз, без монда бары тик яхшылык кылырга килдек”. Коръәннең аерым өлешләре хокук, әхлакый һәм эстетика аспектларын да үз эченә ала. Ислам теориясе һәм гамәле татар халкының кешелеклелек кыйммәтләре системасын барлыкка китерүдә, аның фикерләвен һөм көнкүрешен формалаштыруда зур роль уйный. Гомумән, ул Русиядә яшәүче күп халыкларны үз эченә алып, аларның әхлагы һәм экологиясенең бердәмлеген тудырган.

Ислам дине культурасы, аның экология- педагогик мирасы, рухи-әхлакый һәм гуманистик нигезе тулысынча укыту-тәрбия эшенә булыша һәм укучыларда экология культурасы формалаштыруга ярдәм итә. Шунысын әйтергә кирәк, дин - культураның катлаулы формасы. Ул гасырлар дәвамында фәлсәфәчеләрнең, язучыларның, фикер ияләренең дөньяга карашларын чагылдырган.

Бүгенге шартларда дини экология культурасы, рухи культураның бер өлеше буларак, ниндидер бер формада белем һәм тәрбия бирү системасында урын алырга тиеш. Әлбәттә, бу очракта шуны истә тоту кирәк, Русия, Конституция нигезендә, дөньяви дәүләт, безнең илдә мәктәп чиркәү һәм мәчеттән аерым яши. Әлеге мәсьәлә безнең илдә гене тугел, ә бәлки, барлык цивилизацияле дөньяда шулай хәл ителә.

Экологик белем һәм тәрбия бирү ул укучыларга экологиянең эчтәлеген, законча- лыкларын, төшенчәләрен сөйләп аңлату гына түгел, ә халыкның бай әхлакый-психо- логик мирасын яшь буынга җиткерү чарасы да. Ул балага милли культураны аңларга ярдәм итә, аңа шәхес буларак җитлегергә булыша.

**Җәүдәт Хөсәенов,**
**педагогика фәннәре докторы, КФУ профессоры.** **Суга сусаган - чишмә чистарткан //**
**Мәдәни җомга.- 2013.- № 17.- 26 апрель.- 9 бит. Мәдәни җомга.- 2013.- №18.- 3 май.-9 бит.**

# НИНДИ СУ ЭЧӘСЕЗ?

Бик борынгы заманнардан ук су иң кадерле һәм иң файдалы эчемлекләрдән саналган. Аның дәвалау узлекләрен белгәннәр. Гиппократ, Әбугалисина суны бик яхшы дәвалау чарасы буларак кулланырга киңәш иткән. Анда 65 ләп микроэлемент барлыгы беленгән. Галимнәр шуның егермесенең кеше һәм терлек организмы өчен файдалы булуын исбатлаган. Белгечләр болай ди: «Әгәр дә сез сәламәтлегегезне ныгыту яисә сәләтегезне арттыру, тышкы кыяфәтегезне саклап калу турында уй- лыйсыз икән, бер дә кыйммәтле дарулар эчмәгез. Иң яхшы дару- янәшәгездә: ул - су».

Кайсы ягы белән шулкадәр файдалы соң су? Без аны сусаганда эчә, аш-су әзерләү өчен кулланыла торган төссез, иссез бер сыеклык дип кенә беләбез. Табиблар фикеренчә, организмга су җитми башласа, күзенәкләр кибә һәм алар үз вазифасын үтәми башлый. Мондый хәл даими кабатланса, бавыр күзәнәкләре бертуктаусыз холестерин эшләүгә күчә. Организмда артык холестерин булу йөрәк-кан тамырлары авыруына китерә.

Табиблар кан басымы күтәрелгән очракта да, чамасын белеп кенә су эчәргә киңәш итә. Йоглар исә тәүлегенә 4- 5 л су эчә икән. Безнең өчен норма - 2,2 - 2,5 л, кайбер табиблар 3 л га кадәр эчәргә ярый, диләр.

Әмма шулай да кеше организмы кимендә 70 — 80 процент судан тора, дибез икән, эчә торган суыбызның да сыйфаты яхшы булырга тиеш. Сәламәтлегебез де күп яктан шуңа бәйле.

Әйе, кеше, тулаем тереклек сусыз тора алмый. Су-Ходай тарафыннан бирелгән бик зур байлык. Татарстаныбызда барлыгы 19601 *км* озынлыкта булган 3 меңгә якын эреле-ваклы елга ага. Аларның өслеге 4,4 мең *кв.км,* ягъни бөтен территориябезнең 6,5 процентын алып тора. Җир асты суларыбыз тәүлегенә 3,8 *млн* кубометр кулланырлык.

Татарстан территориясеннән ел дәвамында 232 *куб км* су агып утә, шуның 8,9 куб километры — җирле елгаларныкы.

Татарстанда ике зур сусаклагыч (Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычлары) бар. Зәй һәм Карабаш сусаклагычлары мәйданнары ягыннан бераз кечерәк. Өстевенә, эреле-ваклы 480 буа буылган, аларда 310 *млн куб м* су саклана.

Татарстанда җир асты елгалары да күп. Тик ул байлык тигез таралмаган. Аксубай, Чүпрәле, Чирмешән, Азнакай, Әлмәт кебек суга ярлы төбәклер белән бергә, эре шәһәрләрне тулысынча су белән тәэмин итеп торырлык мул чыганаклы яклар да бар.

Гидрогеологларның, тикшеренүе нетиҗәсендә Казан, Түбән Кама, Чистай, Баулы шәһәрләре суга кытлык кичермәүчелер исемлегенә кертелген. Тик геологлар тарафыннан табылган 36 җир асты елгасының әлегә берничәсе генә файдаланыла башлаган. Баулы, Бөгелмә, Зәй халкы артезиан коесына тоташкан булса да, кайбер районнарның, әйтик, Кама Тамагы районы халкының суга тиенгәне юк. Яңа Чишмә районына аны ташып эчертәләр. Республикада әлегә кадәр иң пычрак су кулланучылар булып Әлмәт саналса, ә иң кыйммәтле суны Чистай халкы эчә. Белгечлернең әйтүенә караганда, эчә торган суның кимендә 1 /3 өлеше җир өсте суларыннан торырга тиеш тик әле бездә бу шарт үтәлүдән бик ерак тора Республика ел дәвамында куллана торган 900 *млн куб м* суның 83 проценты — җир өстендеге сулыклардан чистартып алынган су.

«Нинди су эчесез?» Бүген бу сорау кемнәрне генә борчымый икән? Мөмкинлеге булган нар супер, гипермаркетлардан, Раифадан, Әлдермештен китертелгән суны сатып ала. кемнәрдер 20 шәр литрлы савытларга тутырылган суны фатирына кайтарта. Күпләр, башка чаралары булмагач, краннан килгән суны фильтр аша үткәреп эчәргә мәҗбүр. Әйе, халык һаман да эчә торган чиста суга тилмереп гомер итә.

Бик күптәннән корылган су чистарткыч җиһазларның инде күптән үзлерен чистартыр вакыт җиткән. Сууткәргеч челтәрләрнең 50 проценты тузган, ә 12 процентка якыны санитария таләпләрене җавап бирерлек түгел. Чиста суга аеруча республикабызның көньяк-көнчыгыш районнары тилмерә. Шуңа да «Чиста су программасы халыкны ж,ир асты, ягъни артезиан сулары белән тәэмин итүне күздә тота Әлегә кадер Куйбышев, Түбән Кама сусаклагычлары республикабызның төп су чыганагы булып санала. Алардан тыш, Татарстанда гомуми озынлыгы 6 мең *км* булган Дала Зәе, Шушма, Зур Чирмешән, Зәя, Мишә,

Казансу, Ашыт, Иж, Тойма, Шыя, Чишмә, Ушмы кебек вак елгалар да халыкны су белән тәэмин итүдә зур әһәмияткә ия. Чиста су бирә алырдай күлләр генә дә республикабызда 8700 ләп.

Әйткәнебезчә, «Чиста су» программасында халыкны артезиан суы белән тәэмин итү беренче планга куелган. Алардан тәүлегенә *млн куб м* су алырга була. Бу - бер кешегә

*1.5куб м* артезиан суы туры килә дигән сүз. 2010 елга халыкның ихтыяҗын артезиан суы белән тулысынча тәэмин итү өчен тәүлегенә 1,8 *млн куб м* су кирәк булачак. Хәзер республикабызда 29 артезиан суы чыганагы бар. Бүгенгә әле эре шеһәрләрне артезиан суы белән теэмин итү нибары 12 процент, ә Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт шәһәрләрендә ул 2 процент кына тәшкил итә.

Ни кызганыч, елга-күлләребез, хәтта җир асты суларыбыз да елдан-ел пычрана бара, аларга авыл җирендә тирес, ашлама, агу химикатлар эләгә, ә шәһәр һәм район үзәклә рендә исә предприятиеләрдән төрле зарарлы сәнәгать калдыклары, чүп-чар сулыкларыбызга ташлана. Кулланган суларыбызның да шактый өлеше, чистартылмаган килеш, шул ук елгаларыбызга кире ага тора, чөнки күп кенә предприятиенең чистарту корылмалары искергән, хәтта кайберләрендә бөтенләй юк, ә яңаларын төзергә акча җитми. Димәк, сулыкларыбызны күрә торып һәм даими рәвештә пычратабыз. Мәсәлән, узган ел республикабызның өслек суларына 547 *млн* кубометр ташландык су агызганбыз. Алар составында 6080 *т* җиңел оксидлаша торган кушылмалар (болар бик зарарлы дип санала), 150 г нефть продуктлары, бик күп күләмдә сульфат, хлорид, фосфатлар, 5 *т* чамасы бакыр, 4,6 г цинк һ.б.ш. зарарлы матдәләр эчә торган суларыбызга эләккән.

Татарстанда иң пычрак сулыклар: Зәя, Карлы, Болак, Казансу... Бу исемлеккә яңалары өстәлә тора.

Сусаклагычлардан ел саен 1,3 *млрд куб м* су кулланышка алына. Әйләнештә йөргән су-

5 *млрд куб м.* Ташланган су күләме - 0,7, пычрак килеш күтәрелгәне - 0,6 *млрд куб м.*

Казан халкы, мәсәлән, чисталыгы буенча IV класслы, ягъни «пычранган» дип аталган су эчә. Соңгысы — Иделдән ага торганы. Ә җир астыннан алына торганы (нигездә андый су башкаланың Совет районында) исә үзенең катылыгы белән аерылып тора. Димәк, аның составында да сәламәтлегебез өчен зарарлы химик элементлар бар. Шуңа күрә бөергә, үт юлларына таш утыру, башлыча, суның катылыгына бәйле.

Аңлашылганча, I класслы чиста су урынына "пычранган" категорияле IV класслы су эчү сезнең файдага түгел, чөнки, беренчедән**,** аны чистарту өчен күп чыгымнар кирәк, икенчедән, пычранган суны барыбер чишмә суына әйләндереп булмый. Шул ук хлорны (нигездә ул су чистарту өчен түгел, ә зарарлы микобларны юкка чыгару максатында кулланыла) гына алыйк. Организм өчен хлор үзе дә зарарлы бит.

Россия Дәүләт Думасы спикеры Б.Грызлов чиста су проблемасына багышланган киңәшмәдә эчәргә яраклы суны хлор ярдәмендә чистартудан бөтенләй баш тартырга өндәде. Кызганыч, хәзерге вакытта илебездәге су чистарту системаларының күпчелеге нәкъ менә хлор куллануга нигезләнгән. Ул исә микробларны үтерсә дә, төрле чирләргә «юл» ача торган зарарлы кушылмалар барлыкка китерә. Спикер фикеренчә, хлор технологияләренә каршы җитди көрәш башларга кирәк, чөнки хәзер су чистартуның купкә куркынычсызрак ысуллары бар. Әйтик, күпчелек илдә һәм Россиянең дә кайбер шәһәрләрендә бу максатта алюминий оксихлоридын кулланалар. Ул чагыштырмача зыянсыз һәм арзанрак та. Аны хәтта үзебездә үк җитештерергә мөмкинлек бар. Тик, нилектәндер, безнең республикада әлеге технологияне кулланырга ашыкмыйлар.

Чиста су дигәндә, мөгаен, күпләрдә «Ә хлор белән нишләргә?» дигән сорау туарга мөмкин. Чөнки бездә бит гомер-гомергә суны хлор белән чистарталар. Голландиядән килгән бер галим Казанда суны хлор белән чистартуларын ишеткәч, безнекеләрне «варварлар» дип атаган, ди, имеш. Ә бит бу —һич кенә дә шаяртып әтелгән сүз түгел. Дөрестән дә, хлор органик матдәләр һәм су белән реакциягә кергәч, анда мутагенлы канцерогенлы катнашма барлыкка килә. Мәгълүм булганча, андый катнашма кеше организмында төрле үзгәрешләр, геннарда мутацияләр китереп чыгарырга мөмкин.

Хлорның мутагенлы реакциясе акмый торган суда бигрәк тә көчле бара. Татарстан халлкының 70 процентының нәкъ менә акмый торган Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларындагы суны эчүен истә тотсак, моның нинди зарарлы икәнлеген абайлау кыен

түгел. Шуңа да белгечләр крандагы суның төнлә белән торбаларга тиеп торган өлеше чыгып бетсен өчен иртән бераз агызып торырга һәм крандагы суны банка, кәстрүлләрдә озак салып тотмаска киңәш итәләр.

Ә бит дөньяда, аерым алганда, АКШта, хәзер шәһәр халкы өчен суны озон яки ультрамиләүшә нурлар ярдәмендә чистарталар. Нәтиҗәсе дә югары, арзан да. Тик нигәдер безнең краннардан гына һаман да хлорлы су ага...

Торбалар аша килүче суның пычрак булуын белгечләр дә яшерми. Карлар эрү, ярлардан пычрак суның елгаларга агып төшүе аркасында язын ул бигрәк тә пычрана.

Бернинди чистарту корылмалары да бу мәсьәләне уңай хәл итә алмый. «Әгәр дә Россия халкы тагын 30 ел дәвамында шундый су эчсә, илдә исән кеше калмаячак», —дип кисәтә Кеше экологиясе һәм мохит гигиенасы институты директоры, академик Ю.Рахманин. Әйткәнебезчә, федераль сууткәргечләр системасындагы торбаларның яртысы инде тузып бетеп, алмаштыруга мохтаҗ. Әмма аны алмаштыру өчен озак вакыт кирәк булачак, чөнки Россиядә сүүткәргеч челтәренең гомуми озынлыгы 543 мең *км* тәшкил итә.

Кран суын эчүдән чирканган кешеләр махсус фирмалардан чишмә суын сатып ала анысы. Россиядә шешәләргә тутырылган эчәргә яраклы суның 1500 дән артык төре чыгарыла. Әмма шуның 10—15 төрен генә югары сыйфатлы дип әйтеп була. Санитария-эпидемиология дәүләт күзәтчелеге мәгълүматларына караганда, Россиянең ярты халкы (кайбер районнарда 70 проценты) чистартылмаган су кулланырга мәҗбүр. Илдәге сүүткәргечләр буйлап килгән суның өчтән бере тимергә аеруча бай. Бу исә төрле аллергия һәм кан авыруларына китерергә мөмкин. Җир асты суларыннан файдаланганнар исә гипертония, ашказаны авырулары белән җәфалана.

БМО һәр кешенең чиста суга хокукы барлыгын расласа да, кызганычка, аннан күпчелек халык файдалана алмый. Югыйсә, Россия-үзе суга бай ил: 2,5 *млн* елгасы, 3 *млн* нан артык куле генә бар, алардагы су запасы 26000 *куб км* белән бәяләнә. Су буенда суга сусап яшәү шул буладыр инде, күрәсең.

Галимнәр фаразлавынча, дөнья базарында «кара алтын»ның бәясе төшә (хәзерге кризис моның нәкъ шулай булуын күрсәтә), ә гап-гади төче су нефтьтән күпкә кыйммәтрек булачак. Инде хәзер үк Җир йөзендәге халыкның 1,1 миллиарды хроник сусызлык шартларында яши, ә 2025 елга андыйларның саны 3 миллиардтан артачак. Су җитмәүдән планета халкының 40 проценты интегәчәк.

Гомумән, бүген бөтен дөнья чиста суга кытлык кичерә. Хәтерләсәгез, БМО 2003 елны «Эчә торган су елы» дип игълан иткән иде. ЮНЕСКО карары нигезендә 1993 елдан бирле ел саен 22 март - Бөтендөнья су көне буларак билгеләп үтелә. Бу гамәлләр тиктомалдан гына эшләнмәде. Әйткәнебезчә, бик күп ил, шул исәптән Россия дә, чиста суга тилмерә. Мәсәлән, Казан тирәсендәге чыганакларның күбесе экологик таләпләргә җавап бирми, аерым алганда, Отары, Победилово бистәләрендәгеләресе.

Гомумән, белгечләр Россиянең без яши торган төбәгендә су микроэлементларга ярлы, йод җитми, дип саный. Республикабызның кайбер районнарында бүген үк су проблемасы килеп туды. Мәсәлән, Яңа Чишмә районында берничә скважина бораулап та караганнар, суы бар, әмма «каты» икән. Болгар шәһәрен су белен җирле сусаклагычлар тәэмин итеп тора. Лекин ул суда тимер күп.

Белгәнебезчә, адәм баласы суның төрлесен эчә: чишмәсе булганы шуннан ташый, булмаганы кое, скважина казый, елга суларын чистартып эчә. Сусаганда минераль суга үрелә, тик аны табиблар дәваланыр өчен генә эчәргә текъдим итә. Элек бит теләсе нинди су эчмәгәннәр, нәрсә ярый, нәрсә ярамый икәнлекне белеп эш иткәннәр. Мәсәлән, көмеш суның файдасын белгәнгә күрә суны көмеш савыттан эчкәннәр, коега көмеш акча ташлаганнар. А.Македонскийның батыр сугышчылары авыр походларга чыкканда суны көмеш савыттан гына эчкәннәр. Геронтологлар фикеренчә, көмеш су иммунитетны арттыра, матдәләр алмашын яхшырта, организмны яшәртә. Табиб-геронтолог, «Кызыл хач» җәмгыятенең озак яшәүчеләр клубы президенты С.Яковлев суның бөтен төрләреннән кар суы иң файдалысы, дип саный. Аның сүзләренә караганда, эчә торган суның сыйфаты начарая бара. Җир өстендәге су чыганакларының нибары 1 проценты гына гигиена таләпләренә җавап бирә. Ул мондый хәлне, су чыганакларының пычрана баруы белән бергә, су чистарту технологиясенең

заман таләпләренә җавап бирмәве, су торбаларының нык искергән яки ремонтланмаган булуы белән аңлата.

Республикабызда 3500 су чыганагы, 9 меңнән артык күл исәпләнә. Тик булганнарының, дөресрәге, исән калганнарының да чисталык мәсьәләсе чаң кагарлык. Татарстандагы 2440 тан артык су чыганагының югалуы да Түбән Кама, Куйбышев сусаклагычлары аркасында булуы мәгълүм.

Сулыкларның югала баруына төрле җирдән пычракларның агып керүе дә тәэсир ите. Мәсәлән, урамнардан көрәп түгелгән кар өемнәрендә төрле тоз кушылмалары, нефть продуктлары, гомумән, 30 төргә якын зарарлы, агулы матдә җыела. Ә алар сулыкларга агып төшә.

Елгаларыбызда нинди генә «хәзинә» акмый, суында авыр металлар, бакыр, кургаш дисеңме, марганец, күкерт, аммиак, сульфат, формальдегид, фенол, нефть продуктлары, тагын әллә нинди химик матдәлер бар. Нәрсә агызабыз, ничек пычратабыз -шуны эчәбез. Бавырыбыз гына чыдасын!

Чиста су мәсьәләсе Казан халкы өчен аеруча кискен булып кала. КДМУ профессоры А.Иванов әйтүенчә, Казансу елгасы бассейнындагы артезиан чыганакларында суда сульфат тозлары кирәгеннән артык күп. Норма буенча ул 1 л суда 500 *мг* тирәсе генә булырга тиеш, ә чынлыкта 700 — 800 *мг* нан да артып китә. Мондый суны көн дә эчкән кеше организмында, аеруча балаларныкында, патологик үз гәрешләр башлана. Мәсәлән, ашказаны-эчәк стемасының май һәм аксымны эшкәрту сә ләте бозыла. Нәтиҗәдә, гастрит һәм башка шуның ише авырулар барлыкка килә.

Җир асты чыганаклары бер ук вакытта төче су зонасы буларак та хезмәт итә. Әйтик, Татарстан халкы елына 1 *млрд куб м* су куллана икән шуның 200 мең, кубометры гына елга-күлләрдән алына. Ә калганы нәкъ менә җир асты чыганакларыннан. Шуңа да аларның чисталыгы гаять мөһим. Кызганыч ки, «Гео центр» предприятиесе белгечләре сүзләренә караганда Татарстандагы су чыганакларының 367 се пычрак.

ГОСТ таләпләре буенча барлык кулланыла торган суның 25 проценты җир асты сулары булырга тиеш. Хәзергә бу күрсәткеч 10 процент кына.

«Водоканал» предприятиесе Идел су җибәрү җайланмасының санитария сакланышы зонасы проектын 1996 елда ук эшләгән булган, әмма акча булмау сәбәпле елеге проект (аның бәясе 1 *млн* сумнан артыграк) менә дистә елдан артык инде гамәлгә ашырылмыйча тора.

Елгаларны пычратмау, сулыкларның чисталыгын саклау, гомумән, мохитебез экологиясен сафландыру турындаТатарстан Хөкүмәте шәһәр хакимияте, төрле министрлыклар тарафыннан җитди чаралар билгеләнә. Узган ел гына да 60 лап карар һәм боерык чыгарылган экологлар һәм эпидемиологлар предприятие һем табигый урыннарда, торак кварталлар һәм су чистарту корылмаларында 415 тапкыр тикшерү уткәргән. Нетиҗәдә, бигрәк тә Отар Победилово бистәләре янында Идел суының нык пычрануы ачыкланган.

Табигатьне пычратучылар арасында Казан дары заводы, «Восток-Солод», «Нур-1» ширкәтләре, «Радиоприбор», «Холод», «Полимир” «3 нче тимер-бетон эшленмәләр заводы» акционерлык җәмгыятьләре, Вахитов һем Идел буе районнарының торак идарәләре бар.

Чистарту корылмаларының куәтен арттыру да кичектергесез мәсьәләгә әйләнеп бара. Хәзер алар тәүлегенә 650 мең кубометр юынтык суны чистарта. Башкалабызда яңа микрорайоннар барлыкка килгәч, бу санны 1 *млн* кубометрга җиткерү таләп ителә башлады. Шул сәбәпле кайбер торак кварталларында юынтык сулар тиешенчә чистартылмыйча Иделгә агызыла. Өстәвенә, канализация торбалары урыны-урыны белән 70 процентка кадәр тузган Иске микрорайоннарда салкын су торбалары да шундый хәлдә. Аларның тутыгуы эчә торган су ның сыйфатын тагын да киметүгә китера Иделдәге су алу станциясе исе 60 елдан артык файдаланыла, шунлыктан аның чистарту системасы күптән инде физик яктан искергән.

Экологлар, эпидемиологлар ясаган нәтиҗә шундый: үзебезнең пычратуыбыз аркасында судагы зарарлы матдәләр нормада каралганан 5 тапкырга артып киткән, шул сәбәпле аны кайнатмыйча эчәргә һич ярамый.

Мондый очракта инде кибетләрдә сатылучы шешәле суларга тартылмый хәлең юк. Буген сәүдә нокталарында аларга кытлык юк. Иң куанычлысы шул: күбесе - үзебезнең Татарстан җирлегендәге чыганаклардан алынган сулар. Аларны сатып алганда, барыннан да элек, нәрсәгә игътибар итәргә соң?

Шешәле сулар нигездә 2 төргә: минераль һәм аш-су әзерли торган суга (вода столовая) бүленә. Әгәр аш-су әзерли торганын шул килеш эчәргә яраса, минераль суны табиб белән киңәшкәннән соң гына кулланырга киңәш ителә. Этикеткасында суның исеме, аны җитештергән оешманың (чыганакның) адресы, суның химик составы, скважина номеры, саклау шартлары, саклану срогы күрсәтелә. Сатып алучылар өчен тагын бер мәгълүмат: әгәр җир астыннан алынган суның 1 литрынд атозлар (ионнар) 1г нан кимрәк икән, бу суны эчәргә мөмкин.

Моннан 10—15 еллар элек республикабызда Менделеевск районындагы Иж чыганагыннан алынган минераль су гына җитештерелсә, бүген инде кибетлер «Хотнинская», «Раифский источник» «Олероли», «Кристальная», «Сестрица», «Серебряная вода», «Королевская вода»,“Святой ключ» кебек сулар белен тулган.

Әйтик, «Хотнинская» суы - Арча районындагы Хотня авылы янындагы, «Святой ключ» дигәне Алабуга нефтьчеләре профилакторие территориясендәге чыганаклардан алына. Шулай да бүген республикабызда сатыла торган суның 1 /3 өлешен «Олероли» маркасы тәшкил итә. Белгечләр Лаеш районы Хәерби авылы янындагы артезиан коесыннан алынган суны сәламәтлек өчен бик тә файдалы табигый су дип бәяли.

Әмма бүген республикабызда сатыла торбан сулардан иң чистасы, сәламетлек өчен файдалысы - Карачай-Черкес Республикасында җитештерелгән «Меркурий» минераль суы. Ул хәзер атаклы «Нарзан», «Ессентуки», Боржоми» шифалы сулары белән ярыша, кайбер файдалы сыйфатлары буенча аларны узып та китә. Моны аның 1994 елдан бирле «Россиянең иң яхшы суы» конкурсында җиңеп килүе һәм халыкара сертификатка ия булуы да раслый.

Әлбәттә, шешәле сулар гына халыкның чиста суга булган ихтыяҗын канәгатьләндереп бетерә алмаячак. Бар кешенең дә чиста су ташырга яки аны кибеттен сатып алырга мөмкинлеге дә юк.

Геологлар республикабызның 29 урынында чиста су чыганагы тапкан: алардагы су запасы 1 *млрд* кубометрдан артып китә, ди. Шулардан иң мул сулысы Лаеш районының Столбище авылы янында икән. Ул Казанны көн саен 212 мең кубометр көмештәй саф су белән тәэмин итә алачак. Ә инде әлеге Столбище су агу җайланмасы сафка баскан очракта башкалабыз халкы да чиста су эчә башлар дигән өмет бар.

Халыкны сусыз интектереп булмый бит инде. Сусаганда, авыз тутырып су эчүе ни җитә соң?!

**Язманы журнал өчен Таһир САБИРҖАНОВ әзерләде. НИНДИ СУ ЭЧӘСЕЗ?**
**Мәгариф.-2009.- №3.- 68-71 бит**

***Укучыга***

***Табигатьнең нигезен, аның яшеллеген һәм матурлыгын күрсәтә торган күп чыганакларның берсе – чишмәләр.Җирнең кечкенә генә бер күзәнәгеннән бәреп чыгып, җирле халыкны һәм очраклы юлаучыларны сокландыра, сусауларын баса, кош- кортларны, хайваннарны туендыра торган чишмәләр гасырлар буена халкыбызның теленнән дә, җырларыннан да төшми.***

***Инешләрне, елга-күлләрне, буаларны тукландыра торган чишмә-чыганаклар бүгенге көндә ни хәлдә соң? Халкыбызның борынгы йолаларынан берсе - ул да булса суларны, чишмә - чыганакларны карау һәм чистарту. Районыбызның байтак авылларында бу традицияне дәвам иттерүче ил картлары һәм яшьләр күп. Алар чишмәләр елгалар тирә-юненә агачлар утыртып, ярларны җимерелүдән, саегудан саклыйлар, чишмәләр тирәсен чистарталар, матурлыйлар.***

***2013 ел – экологик культура һәм әйләнә-тирә мохитне саклау елы. Һәркем булдыра алган кадәр чишмә – инешләрнең мул сулы, чиста булуы өчен үзеннән өлеш кертсен иде!***